ҮЗӘКЛӘШКӘН ДИНИ ОЕШМА –
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЕЛМАННАРЫНЫҢ
ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ

# *МӘЧЕТ КАРШЫНДАГЫ КУРСЛАР ӨЧЕН ДИНИ ТӘРБИЯ ПРОГРАММАСЫ*

**КАЗАН**
**2016 / 1437 ел**

ҮЗӘКЛӘШКӘН ДИНИ ОЕШМА –
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЕЛМАННАРЫНЫҢ
ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ

**«Раслыйм»**
ҮДО – ТРМДН рәисе, Мөфти
Камил хәзрәт Сәмигуллин

___________________________

« 1 » сентябрь 2016 ел

**Дини тәрбия программасы Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте Фән һәм мәгариф бүлеге тарафыннан әзерләнде**

*Төзүчеләр:*

**Валиуллин Камил Хәмзә улы** (балалар һәм яшүсмерләр өчен дини тәрбия Программасы)

**Курамшин Ришат Исмәгыйль улы** (өлкәннәр өчен дини тәрбия Программасы)

# *МӘЧЕТ КАРШЫНДАГЫ КУРСЛАРГА ЙӨРҮЧЕ БАЛАЛАР ҺӘМ ЯШҮСМЕРЛӘР ӨЧЕН ДИНИ ТӘРБИЯ ПРОГРАММАСЫ*
**(2 ЯШЬТӘН АЛЫП 17 ЯШЬКӘ КАДӘР)**

أَعُوذُ بِاللهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ بِسْــمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ

إِنَّ الْـحَمْدَ لِلَّهِ نَحْمَدُهُ وَنَسْتَعِينُهُ وَنَسْتَغْفِرُهُ وَنَعُوذُ بِاللهِ مِنْ شُرُورِ أَنْفُسِنَا وَمِنْ سَيِّئَاتِ أَعْمَالِنَا وَمَنْ يَهْدِهِ اللهُ فَلاَ مُضِلَّ لَهُ وَمَنْ يُضْلِلْ فَلاَ هَادِيَ لَه وَأَشْهَدُ أَن لاَ إِلَهَ إِلا اللهُ وَحْدَهُ لا شَرِيكَ لَهُ وَأَشْهَدُ أَنَّ مُـحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ

## Кереш сүз

Ошбу програмна, мәчетләр каршындагы курсларга һәм якшәмбе мәктәпләренә йөрүче балаларның төрле яшьтә булуларын исәпкә алып, өч өлешкә бүленеп эшләнде: 1) мәктәпкәчә яшьтәге 2 - 6 яшьлек балалар өчен; 2) башлангыч мәктәп яшендәге 7-10 яшьлек укучылар өчен; 3) төп һәм урта мәктәп яшендәге 11-17 яшьлек үсмерләр өчен.

**2 - 6 яшьлек балалар өчен дини тәрбия программасы** биш еллык дип исәпләнгән: 1нче ел – 2-3 яшьлекләр өчен; 2нче ел – 3-4 яшьлекләр өчен; 3нче ел – 4-5 яшьлекләр өчен; 4нче ел – 5-6 яшьлекләр өчен; 5нче ел – 6-7 яшьлекләр өчен.

Беренче ел укучы 2 яшьлек балаларга дәресләр әниләре белән бергә, сөйләм үсешенә аерым игътибар биргән хәлдә, уен рәвешендә, шигырь һәм мөнәҗәтләр файдаланып, артикуляцион һәм бармаклы күнегүләр ярдәмендә алып барыла. Дәрес дәвамы: 30 минут, атнага 2 тапкыр. Укытыла торган фәннәр: гакыйдә, әдәп-әхлак, Коръән Кәрим, фикыһ һәм Ислам тарихы.

Икенче ел укучы 3-4 яшьлек балаларга укулар әниләрсез алып барыла. Дәрес дәвамы 1 сәгать, атнага 2 тапкыр. Укытыла торган фәннәр: гакыйдә, әдәп-әхлак, Коръән Кәрим, фикыһ һәм Ислам тарихы.

Өченче ел (4-5 яшьлекләр), дүртенче ел (5-6 яшьлекләр) һәм бишенче ел (6-7 яшьлекләр) укучы балаларга дәрес дәвамы 1-1,5 сәгать, атнага 3 тапкыр. Укытыла торган фәннәр: гакыйдә, әдәп-әхлак, гарәп хәрефләре, Коръән Кәрим, фикыһ һәм Ислам тарихы.

**7 - 10 яшьлек балалар өчен дини тәрбия программасы** дүрт еллык дип исәпләнгән: 1нче ел – 7-8 яшьлекләр өчен; 2нче ел – 8-9 яшьлекләр өчен; 3нче ел – 9-10 яшьлекләр өчен; 4нче ел – 10-11 яшьлекләр өчен. Дәрес дәвамы 4 сәгать, атнага 1 тапкыр яисә атнага ике тапкыр, дәрес дәвамы 2 сәгать. Укытыла торган фәннәр: гакыйдә, әдәп-әхлак, гарәп хәрефләре, тәҗвид, Коръән Кәрим, фикыһ һәм Ислам тарихы.

**11 - 17 яшьлекләр өчен дини тәрбия программасы** җиде еллык дип исәпләнгән: 1нче ел – 11-12 яшьлекләр өчен; 2нче ел – 12-13 яшьлекләр өчен; 3нче ел – 13-14 яшьлекләр өчен; 4нче ел – 14-15 яшьлекләр өчен; 5нче ел – 15-16 яшьлекләр өчен; 6нчы ел – 16-17 яшьлекләр өчен; 7нче ел – 17-18 яшьлекләр өчен. Дәрес дәвамы 4 сәгать, атнага 1 тапкыр. Укытыла торган фәннәр: гакыйдә, әдәп-әхлак, гарәп хәрефләре, тәҗвид, Коръән Кәрим, фикыһ һәм Ислам тарихы.

Әлеге программаның максаты һәм бурычы – мәчетләр каршындагы башлангыч дини белем һәм тәрбия бирү курсларында Ислам диненең нигезләрен өйрәнү, балаларның Ислам динебез кушканнарын кабул итеп, мөселман булып формалашуы. Курсларның эшчәнлеген тиешле рәвештә оештыру Ислам динен ата-бабаларыбыз алып барган рәвештә дәвам итү эшенә зур өлеш кертү булыр иде. Шуның өчен бу курсларны тиешле уку программалары, белемле укытучылар һәм тиешле уку-укыту әсбаплары белән тәэмин итү сорала.

Тәрбия – ул кешене бу дөньяда һәм Ахирәттә бәхеткә ирештерә торган иң лаеклы юл. Чөнки ул шәхеснең бөтен якларын үстерә, үзенә һәм башка кешеләргә карата яхшылык эшләргә теләк тудыра, фәзыйләтле булган нәрсәләргә гадәтләндерә, яхшылык белән начарлыкны аера белүне өйрәтә, ялкаулык һәм битараф булуны бетерә. Тәрбия ул – сәламәт җисем һәм сәламәт акыл, дөрес яшәү рәвешен булдыручы нәрсә. Боларның бөтенесен исә, дини кыйммәтләргә таянып эш иткәндә генә булдырырга мөмкин.

Ризаэтдин бин Фәхреддин әйтте: «Дин кешелек җәмгыяте барлыкка килеп яши башлаганнан алып, әдәп, әхлак, шәфкать, мөрәүвәт, изгелек, итагатьлелек, кешелеклелек, намус, сафлык, пакьлек, гаделлек, яхшылык һәм башка бик күп күркәм төшенчәне эченә алган һәм бозык эшләрдән тыелып, яхшы эшләр генә эшләргә өндәгән кануннар тупланмасы һәм тәртип, тәрбия һәм әхлакның нигезе, гаиләдә тәртип сакчысы, тормышның төзек, гомернең бәрәкәтле узуына сәбәп».

Балаларга белем һәм тәрбия биргән вакытта күрсәтмәлелекне киң кулланырга мөмкинлек бирүче методларга, кыйссалар белән тәрбияләүгә аерата зур урын бирелергә тиеш. Шулай ук, Ислам тәрбиясе укытучысы балаларны алар хис иткән һәм күзәтеп торган нәрсәләргә, Галәмдә булган гаҗәеп нәрсәләргә, Аллаһы Тәгалә бар иткән мәхлүкатларга, аларга ачык һәм яшерен булган нигъмәтләре белән тулыландырган нәрсәләргә юнәлдерү кирәк.

Мөгаллимнәрнең укырга килүчеләр белән уртак тел табуы, укуга карата кызыксындыру тудыру да бик мөһим. Моның өчен гыйлем бирүче мөгаллимнәр үз белемнәрен күтәрү, әхлакый сыйфатларын камилләштерү өстендә даими рәвештә эшләүне туктатмаска, китаплар укып, вәгазьләр тыңлап, мәгълүматларын киңәйтергә, яңа эш методикалары белән танышып барырга тиешләр.

Шунысы да мөһим: һәр программа уку-укыту процессында сыналырга (“опробация” үтәргә) тиеш. Шуңа күрә алга таба ул мөгаллимнәрнең, тәрбиячеләрнең киңәш-тәкъдимнәрен исәпкә алып, әле яңартылырга, тагын да камилләшергә мөмкин. Моның өчен, дини мәгърифәтебез торышы, үсеше өчен битараф булмыйча, эшлекле тәкъдимнәребезне җиткерергә, уртага салып сөйләшергә, киңәшергә кирәк.

Башлангыч дини гыйлем – ул ислам мәгарифенең чишмә башы. Шушы чишмә “суын” авыз итәргә теләүчеләргә дин белеме биреп, хәерле, файдалы эшләр башкарырга язсын, изге эшебездә Аллаһы Тәгалә Үзе ярдәмче булып, әҗер-савапларын ахирәттә күрергә насыйп кылсын.

# 2-6 ЯШЬЛЕК БАЛАЛАР ӨЧЕН ДИНИ ТӘРБИЯ ПРОГРАММАСЫ

## Беренче ел (2 яшьлекләр)

Дәресләр әниләр һәм балалар белән бергә, сөйләм үсешенә аерым игътибар биргән хәлдә, уен рәвешендә, шигырь һәм мөнәҗәтләр файдаланып, артикуляцион һәм бармаклы күнегүләр ярдәмендә алып барыла.

*Дәрес дәвамы: 30 минут, атнага 2 тапкыр*

### 1. Гакыйдә

Исламның биш нигезе: беренчесе - ике шәһадәт китерү; икенчесе - намаз уку; өченчесе - ураза тоту; дүртенчесе - зәкят бирү; бишенчесе - хаҗ кылу (Исламның биш нигезен татар телендә укытучы тарафыннан әйтелүе, балаларның әниләре белән бергә укытучы артыннан кабатлаулары).

**Аллаһы Тәгаләгә иман.** Аллаһы Тәгалә барча нәрсәләрнең Бар итүчесе. Аллаһы Тәгалә барча нәрсәләрне кешегә файда булсын өчен Бар итүе. Аллаһы Тәгалә кешегә биргән санаусыз нигъмәтләрне күрә белү һәм шулар өчен Аллаһы Тәгаләгә шөкерле булу. Аллаһы Тәгалә Ризыкландыручы. Аллаһы Тәгалә Рәхимле, Шәфкатьле.

Аллаһы Тәгаләнең исемнәре: Әр-Рахмәнү, әр-Рахиму, әл-Мәликү, әл-Куддүсү, әс-Сәләәмү, әл-Мүъминү, әл-Мүһәйминү, әл-Гәзизү, әл-Җәббәру, әл-Мүтәкаббиру, әл-Халику, әл-Бәриү, әл-Мүсаввиру, әл-Гаффәру, әл-Каһһәру (тыңлау һәм тел белән кабатлап үзләштерү рәвешендә алып барыла).

Мөхәммәд с.г.в.с. не Аллаһы Тәгаләнең илчесе дип тануыбыз. Аның исемен әйткән вакытта яисә ишеткәндә «Салләллаһү галәйһи вә сәлләм» («Аңа Аллаһның сәламе булсын») дип хөрмәт белән искә алу кирәклеге.

**Төп әдәбият:**

1. Вәлиуллин К.Х. Ислам тәрбиясе. 1-4 сыйныфлар өчен дәреслек. — Казан: Идел-Пресс, 2016 - 256 б.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Әдһәмов Г. Гакыйдә (Иман нигезләре). Уку әсбабы. Казан: Хузур, 2014. – 160 б.

2. Максуди Ә. Гыйбадәте исламия. — Казан: Идел-Пресс, 2013.

### 2. Әдәп-әхлак

«Бисмилләһир-рахмәнир-рахим» сүзләрен һәрвакыт әйтеп йөрүнең кирәклеге.

Сәламләшү һәм саубуллашу әдәпләре. Мөселман бала, кардәше белән очрашканда, «Әс-сәламү галәйкүм вә рахмә-тул-лаһи вә бәракә-түһү»,

ә сәлам алучы «Вә галәй-күмүс-сәлам вә рахмәтул-лаһи вә бәракәтүһү» дип сәламләшүе. Сәлам биргәндә бер-берләренең кулларын кысулары.

Ашау-эчү әдәпләре һәм догалары.

Уен әдәпләре.

Тәннең, авыз-тешләрнең, чәчләрнең, кулларның һәм киемнең чисталыгы.

Белем алу әдәпләре. Дәрес алдыннан «Рабби зидни гыйлмән нәфигән» догасын өйрәтү.

«Раббәнә этинә фиддунья хәсәнәтән вә фи-л-әхырати хәсәнәтән вә кыйнә газәбән-нәр» догасын өйрәтү.

**Төп әдәбият:**

1. Вәлиуллин К.Х. Ислам тәрбиясе. 1-4 сыйныфлар өчен дәреслек. — Казан: Идел-Пресс, 2016 - 256 б.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Аль-Газали Абу Хамид. Адабы. Казань: Идел-Пресс, 2013.
2. Балаларга үгет-нәсыйхәт. Яңартылган икенче басма. — Казан: «Дом печати», 2002. — 175 б.
3. Вәлиуллин К.Х. Әхлак. Мәчетләр каршындагы өч еллык курслар өчен дәреслек. Казан: «Казан Нуры» каршындагы «Шамил» мәдрәсәсе, 2015/1437. – 56 б.
4. Фазлыев Җ. Иманлы бала. Тәрбия турында. — Казан: «Идел-пресс» басмаханәсе, 2003. — 144 бит.
5. Фазлыев Җ. Локман Хәким нәсыйхәтләре. Казан: Хузур, 2014.

## 3. Коръән Кәрим

Түбәндәге сүрәләрне укытучы балаларга укый, балалар әниләре белән бергә укытучы артыннан кабатлыйлар һәм мөмкин булган хәтле ятлыйлар:

- Әл-Фәтихә.
- Әл-Ихлас.
- Әл-Фәләк.
-Ән-Нәс.

**Төп әдәбият:**

1. Һәфтияк шәриф. – Казан, 2012. – 152 бит.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Коръән Шәриф (Казан басмасы).

## 4. Фикыһ

Мөселман Раббысы Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кыла: шәһадәт кәлимәсен әйтә, көненә биш вакыт намаз укый, зәкят бирә, Рамазан аенда ураза тота, хаҗ кыла.

Таһәрат алуга өйрәтү.

Азан тыңлау, аның сүзләрен кабатлап бару.

Намазның исемнәре, хәрәкәтләре, әдәпләре.

**Төп әдәбият:**

1. Вәлиуллин К.Х. Ислам тәрбиясе. 1-4 сыйныфлар өчен дәреслек. — Казан: Идел-Пресс, 2016 - 256 б.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Максуди Ә. Гыйбадәте исламия. – Казан: «Матбугат йорты» нәшрияты, 2012.

### 5. Ислам тарихы

**Пәйгамбәрләр тарихы:** Адәм пәйгамбәр гәләйһис-сәләм кыйссасы. Нух пәйгамбәр гәләйһис-сәләм кыйссасы.

**Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в.с. нең тормышыннан:** Мөхәммәд с.г.в.с. нең гаиләсе; Фил вакыйгасы; Мөхәммәд с.г.в.с. нең бала чагы; Мөхәммәд с.г.в.с. нең Әбү Талибның тәрбиясендә булуы.

**Төп әдәбият:**

1. Вәлиуллин К.Х. Ислам тәрбиясе. 1-4 сыйныфлар өчен дәреслек. — Казан: Идел-Пресс, 2016 - 256 б.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Бикбулат С. Хәзрәти Мөхәммәд. – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2014.
2. Фәхреддин Р. Мөхәммәд. – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2015.

## Икенче ел (3 яшьлекләр)

*Дәресләр әниләрсез алып барыла. Дәрес дәвамы 1 сәгать, атнага 2 тапкыр*

### 1. Гакыйдә

Ислам дине. Ислам диненең Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в.с. аркылы кешеләргә бирелгән Аллаһы Тәгаләнең дине булуы. Мөэмин һәм мөселман төшенчәләре. Без – мөселманнар.

**Аллаһы Тәгаләгә иман**. Безнең Раббыбыз – Аллаһ. Аллаһ барча нәрсәләрне дә Барлыкка китерүче. Аллаһ безне гыйбадәт кылыр өчен бар иткән. Аллаһ ел фасылларын бар иткән. Аллаһ кешене бар иткән. Аллаһ кешегә куллар-аяклар, колаклар һәм күзләр биргән. Аллаһ кешегә борын биргән. Аллаһ кешегә авыз биргән.

Аллаһы Тәгаләнең исемнәре: Әл-Вәһһәәбү, әр-Раззәәку, әл-Фәттәәхү, әл-Гәлиимү, әл-Каабиду, әл-Бәәситу, әл-Хаафиду, әр-Раафигү, әл-Мүгиззү, әл-Мүзиллү, әс-Сәмиигү, әл-Бәсыыру, әл-Хәкәмү, әл-Гәдлү, әл-Ләтыыфү.

Мөхәммәд с.г.в.с. нең Ислам динен өйрәтүе өчен, барча халыкларга җибәрелгәнлеге. Аның тормышын үзебезгә үрнәк итеп алырга тырышырга кирәклеге.

*Радыту би-Лләһи Раббән вә бил-Исләми динән вә би-Мүхәммәдин Расүлән* (Аллаһның Патша булуыннан, Исламның дин булуыннан, Мөхәммәд с.г.в.с. нең Пәйгамбәр булуыннан разый булдым) дигән доганы өйрәтү.

**Төп әдәбият:**

1. Вәлиуллин К.Х. Ислам тәрбиясе. 1-4 сыйныфлар өчен дәреслек. — Казан: Идел-Пресс, 2016 - 256 б.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Әдһәмов Г. Гакыйдә (Иман нигезләре). Уку әсбабы. Казан: Хузур, 2014. – 160 б.

2. Максуди Ә. Гыйбадәте исламия. — Казан: Идел-Пресс, 2013. — 112 б.

## 2. Әдәп-әхлак

Әтием һәм әнием. Әти-әнигә итагать итү, аларның икесен дә ярату, аларга хөрмәт күрсәтү һәм аларга чын күңелдән хезмәт итү кирәклеге. Әнинең өстенлеге. Әтинең өстенлеге. Әти-әнигә карата булган бурычлар.

Туганнарым һәм якыннарым. Мөселман бала тәрбияле булып, Аллаһы Тәгалә сөйгәннәрне эшләве  һәм туганнарын, якыннарын яратуы. Туганнар ата-аналардан соң иң якын кешеләр булуы. Туганнарга һәм якыннарга карата булган бурычлар.

Кардәшләрем (дусларым) һәм күршеләрем. Мөселман бала тәрбияле булып, Аллаһы Тәгалә сөйгәннәрне эшләве, кардәшләрен (дусларын) һәм күршеләрен хөрмәт итүе. Кардәшләр (дуслар) ата-аналардан һәм туганнардан соң иң якын кешеләр булуы. Кардәшләремә (дусларыма) һәм күршеләремә карата бурычлар.

Сәламләшү әдәбе. Нинди хәлдә сәлам бирелмәс икәнлеге турында.

Бәдрәфкә керү әдәпләре һәм догалары.

**Төп әдәбият:**

1. Вәлиуллин К.Х. Ислам тәрбиясе. 1-4 сыйныфлар өчен дәреслек. — Казан: Идел-Пресс, 2016 - 256 б.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Аль-Газали Абу Хамид. Адабы. Казань: Идел-Пресс, 2013.

2. Балаларга үгет-нәсыйхәт. Яңартылган икенче басма. — Казан: «Дом печати», 2002. — 175 б.

3. Вәлиуллин К.Х. Әхлак. Мәчетләр каршындагы өч еллык курслар өчен дәреслек. Казан: «Казан Нуры» каршындагы «Шамил» мәдрәсәсе, 2015/1437. – 56 б.
4. Фазлыев Җ. Иманлы бала. Тәрбия турында. — Казан: «Идел-пресс» басмаханәсе, 2003. — 144 бит.
5. Фазлыев Җ. Локман Хәким нәсыйхәтләре. Казан: Хузур, 2014.

### 3. Коръән Кәрим

Түбәндәге сүрәләрне укытучы балаларга укый, балалар укытучы артыннан кабатлыйлар һәм ятлыйлар:

- Әл-Фәтихә.
- Әл-Ихлас.
- Әл-Фәләк.
- Ән-Нәс.
- Әл-Гаср.

**Төп әдәбият:**

1. Һәфтияк шәриф. – Казан, 2012. – 152 бит.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Коръән Шәриф (Казан басмасы).

### 4. Фикыһ

Малайларның гаурәт җирләре нидән гыйбарәт икәнлеген аңлату. Кызларның гаурәт җирләре нидән гыйбарәт икәнлеген аңлату. Гаурәт җирләрен каплап йөрү тиеш икәнлеге.

Намазларның вакытлары.

Кыйбланың аңлатмасы. Кыйбланың Мәккәдә урнашкан икәнлеге.

Намазга ният кылу.

Азан һәм камәт нинди гамәлләр төренә керүе. Азанны малайларга әйттерү.

**Төп әдәбият:**

1. Вәлиуллин К.Х. Ислам тәрбиясе. 1-4 сыйныфлар өчен дәреслек. — Казан: Идел-Пресс, 2016 - 256 б.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Максуди Ә. Гыйбадәте исламия. – Казан: «Матбугат йорты» нәшрияты, 2012.

### 5. Ислам тарихы

**Пәйгамбәрләр тарихы:** Һүд пәйгамбәр гәләйһис-сәләм кыйссасы. Ибраһим һәм Исмәгыйль пәйгамбәрләр гәләйһис-сәләм пәйгамбәрләр кыйссалары. Йосыф пәйгамбәр гәләйһис-сәләм кыйссасы.

**Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в.с. нең тормышыннан:** Кәгъбәне төзү. Хәдичәгә өйләнү. Вәхинең иңдерелә башлавы. Исламга өнди башлау. Беренче мөселманнар. Хабәшстанга күчеп китү. Олы кайгы елы. Таифка бару. Мөхәммәд с.г.в.с. нең Мәккәдән Коддуска төнге сәяхәте һәм күккә ашуы. Пәйгамбәр с.г.в.с. нең Мәдинәгә һиҗрәт кылуы (күчеп китүе).

**Татар халкының ислам тарихы**: Борынгы бабаларыбыз булган болгарларның Ислам динен кабул итүе. Багдадтан Болгарга илчеләр килүе. Әхмәд ибн Фадланның юлъязмалары. Болгар иле. Болгар һәм Биләр шәһәрләре.

**Төп әдәбият:**

1. Вәлиуллин К.Х. Ислам тәрбиясе. 1-4 сыйныфлар өчен дәреслек. — Казан: Идел-Пресс, 2016 - 256 б.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Бикбулат С. Хәзрәти Мөхәммәд. – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2014.
2. Фәхреддин Р. Мөхәммәд. – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2015.
3. Ислам дине нигезләре – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2016.

## Өченче ел (4 яшьлекләр)

*Дәрес дәвамы 1-1,5 сәгать, атнага 3 тапкыр*

### 1. Гакыйдә

**Аллаһы Тәгаләгә иман**. Аллаһ гаҗәеп хайваннарны бар иткән. Аллаһ су хайваннарын бар иткән. Аллаһ гаҗәеп бөҗәкләрне бар иткән. Күбәләк ничек барлыкка килә? Аллаһ кошларны бар иткән. Аллаһ үсемлекләрне бар иткән. Аллаһ җиләк-җимешләрне, яшелчәләрне бар иткән. Аллаһ чәчәкләр бар иткән. Чәчәкнең барлыкка килүе. Аллаһ кыргый хайваннарны бар итүче. Баканың барлыкка килүе. Аллаһ бал кортын бар иткән.

Аллаһы Тәгаләнең исемнәре: Әл-Хабииру, әл-Хәлииму, әл-Гәзыйму, әл-Гафүүру, әш-Шәкүүру, әл-Гәлийү, әл-Кәбииру, әл-Хәфиизу, әл-Мукиитү, әл-Хәсиибү, әл-Җәлиилү, әл-Кәриимү, әр-Ракыйбү, әл-Мүҗиибү, әл-Вәәсигү.

**Фәрештәләргә иман китерү.** Фәрештәләр алар Аллаһы Тәгаләнең бик итагатьле коллары, нурдан яратылганнар, Аллаһы Тәгаләгә һәрвакыт гыйбадәт итәләр, Аңа мактау һәм тәсбих әйтеп торалар, Аллаһы Тәгалә аларга нәрсә кушса, шуңа һич каршы килмичә, аны җиренә җиткереп башкаралар, гөнаһлы эшләрне эшләмиләр. Фәрештәләрнең сыйфатлары. Фәрештәләрнең төрләре.

**Төп әдәбият:**

1. Вәлиуллин К.Х. Ислам тәрбиясе. 1-4 сыйныфлар өчен дәреслек. — Казан: Идел-Пресс, 2016 - 256 б.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Әдһәмов Г. Гакыйдә (Иман нигезләре). Уку әсбабы. Казан: Хузур, 2014. – 160 б.

2. Максуди Ә. Гыйбадәте исламия. — Казан: Идел-Пресс, 2013. — 112 б.

3. Ислам дине нигезләре – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2016.

## 2. Әдәп-әхлак

**Күркәм холыклар:**

Тугрылык.

Мәрхәмәтлек һәм йомшак күңеллелек.

Ярдәмләшү һәм юмартлык. Гомәрнең (Аллаһ аннан разый булсын) ярдәм итүе (кыйсса).

Әдәп һәм хая.

Шөкер, шөкер итү, рәхмәтле була белү.

**Ислам әдәпләре һәм догалары:**

Мәҗлес әдәпләре һәм догалары.

Авыруның хәлен белү әдәпләре һәм догалары.

Төчкерү әдәпләре һәм зикер-догалары.

**Төп әдәбият:**

1. Вәлиуллин К.Х. Ислам тәрбиясе. 1-4 сыйныфлар өчен дәреслек. — Казан: Идел-Пресс, 2016 - 256 б.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Аль-Газали Абу Хамид. Адабы. Казань: Идел-Пресс, 2013.

2. Балаларга үгет-нәсыйхәт. Яңартылган икенче басма. — Казан: «Дом печати», 2002. — 175 б.

3. Вәлиуллин К.Х. Әхлак. Мәчетләр каршындагы өч еллык курслар өчен дәреслек. Казан: «Казан Нуры» каршындагы «Шамил» мәдрәсәсе, 2015/1437. – 56 б.

4. Фазлыев Җ. Иманлы бала. Тәрбия турында. — Казан: «Идел-пресс» басмаханәсе, 2003. — 144 бит.

5. Фазлыев Җ. Локман Хәким нәсыйхәтләре. Казан: Хузур, 2014.

6. Ислам дине нигезләре – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2016.

## 3. Гарәп хәрефләре

Әлифбаны уку.

Өс хәрәкә (фәтхә), ас хәрәкә (кәсрә) һәм өтер хәрәкә (даммә).

" ا " хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"ر" хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"ز" хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"م" хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"ت" хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"ن" хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"ي " хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"ب" хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"ك" хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"ل" хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"و" хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

" ه " хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"ف" хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"ق" хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

**Төп әдәбият:**

1. Әхмәдһади Максуди. Мөгаллим сәни. – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2015.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Вәлиуллин К. Гарәпчә язу. 1 нче һәм 2 нче өлеше. – Казан: «Иман» нәшрияты, 1996.
2. Курамшин Р.И. Башлангыч мәдрәсәләр һәм мәчетләр каршындагы курслар өчен тәҗвид дәреслеге. – Казан: "Хузур" нәшрияты, 2016.

## 4. Коръән Кәрим

Түбәндәге сүрәләрне укытучы балаларга укый, балалар укытучы артыннан кабатлыйлар һәм ятлыйлар:

- Әл-Кәүсәр.
- Әл-Кәфирун.
-Ән-Нәср.
- Әл-Мәсәд.

**Төп әдәбият:**

1. Һәфтияк шәриф. – Казан, 2012. – 152 бит.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Коръән Шәриф (Казан басмасы).

## 5. Фикыһ

Намазны җәмәгать белән укуның өстенлекләре.

Намаз эчендә һәм соңында укылачак зикерләр: сәнә, әгүзе, сүрәи Фатиха, кыска сүрәләр, рукүгъ тәсбихе, тәсмиг, тәхмид, сәҗдә тәсбихе,

тәшәһһөд, салават, дога аяте, сәлам, сәлам догасы.

Намаздан соң укыла торгаан тәсбих һәм догалар.

**Төп әдәбият:**

1. Вәлиуллин К.Х. Ислам тәрбиясе. 1-4 сыйныфлар өчен дәреслек. — Казан: Идел-Пресс, 2016 - 256 б.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Максуди Ә. Гыйбадәте исламия. – Казан: «Матбугат йорты» нәшрияты, 2012.

### 6. Ислам тарихы

**Пәйгамбәрләр тарихы:** Әюп пәйгамбәр гәләйһис-сәләм кыйссасы. Муса пәйгамбәр гәләйһис-сәләм кыйссасы. Дауд пәйгамбәр гәләйһис-сәләм кыйссасы.

**Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в.с. нең тормышыннан:** Худәйбия вакыйгасы. Патшаларга һәм хакимнәргә илчеләр җибәрү. Хайбәр ныгытмасын алу. Аллаһы Тәгалә бүләк иткән гыйбадәт. Мәккәи Мөкәррәмне фәтех итү.

**Татар халкының ислам тарихы:** Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорында Ислам дине. Шәһәрләре. Кол Шәриф. Кырым ханлыгы. Себер ханлыгы. Әстерхан ханлыгы.

**Төп әдәбият:**

1. Вәлиуллин К.Х. Ислам тәрбиясе. 1-4 сыйныфлар өчен дәреслек. — Казан: Идел-Пресс, 2016 - 256 б.

**Өчен өстәмә әдәбият:**

1. Бикбулат С. Хәзрәти Мөхәммәд. – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2014.
2. Фәхреддин Р. Мөхәммәд. – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2015.
3. Ислам дине нигезләре – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2016.

## Дүртенче ел (5 яшьлекләр)

### 1. Гакыйдә

**Аллаһы Тәгаләгә иман**. Аллаһ барысын да күрә. Аллаһ ризык бирүче. Аллаһ табигать күренешләрен бар иткән. Аллаһ җирне бар иткән. Аллаһ күкләрне бар иткән. Аллаһ галәмне һәм планеталарны бар иткән. Аллаһ тауларны, чүлләрне һәм океаннарны бар иткән. Аллаһы Тәгалә кешегә транспортны буйсындырган. Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән кеше төрле әйберләр ясарга өйрәнгән. Безне бар итүче Аллаһ. Аллаһны ярату. Аллаһ - бөтен дөньяны бар итүче. Аллаһы Тәгаләгә шөкерләребезне белдерүебез.

Аллаһы Тәгаләнең исемнәре: Әл-Хәкиимү, әл-Вәәдүүдү, әл-Мәҗиидү, әл-Бәәгисү, әш-Шәһиидү, әл-Хәкку, әл-Вәкиилү, әл-Кавийү, әл-Мәтиину,

әл-Вәлийү, әл-Хәмиидү, әл-Мүхсы, әл-Мүбдиү, әл-Мүгиидү, әл-Мүхии.

**Пәйгамбәрләргә иман китерү.** Кешеләргә дин хөкемнәрен өйрәтү өчен Аллаһы Тәгалә бик күп пәйгамбәрләр җибәргән. Иң беренче пәйгамбәр Адәм гәләйһис-сәләм, ахыргы пәйгамбәр Мөхәммәд с.г.в.с. Коръән Кәримдә шушы 25 пәйгамбәрнең исемнәре искә алына: Адәм, Нух, Идрис, Салих, Ибраһим, Һуд, Лут, Юнус, Исмәгыйль, Исхак, Ягъкуб, Йосыф, Әюп, Шогаеб, Муса, Һарун, Әл-Ясәгъ, Зүл-Кифел, Дауд, Зәкәрия, Сөләйман, Ильяс, Яхья, Гайсә, Мөхәммәд (Аларның барысына да Аллаһның сәламе һәм салаваты булса иде).

**Китапларга иман китерү.** Аллаһы Тәгалә дин хөкемнәрен аңлатып, пәйгамбәрләренә Китаплар иңдергән. Аларда Аллаһның кешеләргә әмер иткән һәм тыйган нәрсәләре язылган. Үзенең ахыргы Китабы Коръән-Кәримдә Аллаһы Тәгалә кешеләргә иңдерелгән биш изге Китапның исемнәрен китерә: 1. Сәхифәләр (Ибраһим гәләйһис-сәләмгә иңдерелде); 2. Зәбур (Дауд гәләйһис-сәләмгә иңдерелде); 3. Тәүрат (Муса гәләйһис-сәләмгә иңдерелде); 4. Инҗил (Гайсә гәләйһис-сәләмгә иңдерелде); 5. Коръән Кәрим (Мөхәммәд с.г.в.с. гә иңдерелде). Коръән Кәримне Аллаһы Тәгалә Рәсүлебез Мөхәммәд с.г.в.с. гә 23 ел дәвамында Җәбраил г.с. фәрештә аркылы иңдергән. Ул Пәйгамбәребез с.г.в.с. нең могҗизасы була. Аллаһы Тәгалә аны гарәп телендә иңдергән. Коръән Кәрим Аллаһы Тәгалә тарафыннан иңдерелгән ахыргы Китап булып санала.

**Төп әдәбият:**

1. Вәлиуллин К. Ислам гакыйдәсе (Иман нигезләре). Уку әсбабы. Казан: «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе, 2016/1437. – 215 бит.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Әдһәмов Г. Гакыйдә (Иман нигезләре). Уку әсбабы. Казан: Хузур, 2014. – 160 б.

2. Максуди Ә. Гыйбадәте исламия. — Казан: Идел-Пресс, 2013. — 112 б.

3. Ислам дине нигезләре – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2016.

### 2. Әдәп-әхлак

**Күркәм холыклар:**

Тырышлык.

Сабырлык.

Әманәт. Гомәр әл-Фәрук кыйссасы.

Локман Хәкимнең улына әйткән нәсыйхәтләре.

**Ислам әдәпләре һәм догалары:**

Йокы әдәпләре һәм укыла торган догалары.

Юл әдәпләре һәм догалары.

Мәчет әдәпләре һәм догалары.

Киенү әдәпләре.

**Төп әдәбият:**

4. Вәлиуллин К.Х. Ислам тәрбиясе. 1-4 сыйныфлар өчен дәреслек. — Казан: Идел-Пресс, 2016 - 256 б.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Аль-Газали Абу Хамид. Адабы. Казань: Идел-Пресс, 2013.
2. Балаларга үгет-нәсыйхәт. Яңартылган икенче басма. — Казан: «Дом печати», 2002. — 175 б.
3. Вәлиуллин К.Х. Әхлак. Мәчетләр каршындагы өч еллык курслар өчен дәреслек. Казан: «Казан Нуры» каршындагы «Шамил» мәдрәсәсе, 2015/1437. – 56 б.
4. Фазлыев Җ. Иманлы бала. Тәрбия турында. — Казан: «Идел-пресс» басмаханәсе, 2003. — 144 бит.
5. Фазлыев Җ. Локман Хәким нәсыйхәтләре. Казан: Хузур, 2014.
6. Ислам дине нигезләре – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2016.

## 3. Гарәп хәрефләре

"ش" хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"س" хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"ث" хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"ص" хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"ط" хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"ج" хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"خ" хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"ح" хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"غ" хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"ع" хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"د" хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"ض" хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"ذ" хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"ظ" хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

**Төп әдәбият:**

1. Әхмәдһади Максуди. Мөгаллим сәни. – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2015.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Вәлиуллин К. Гарәпчә язу. 1 нче һәм 2 нче өлеше. – Казан: «Иман» нәшрияты, 1996.

2. Курамшин Р.И. Башлангыч мәдрәсәләр һәм мәчетләр каршындагы курслар өчен тәҗвид дәреслеге. – Казан: “Хузур” нәшрияты, 2016.

## 4. Коръән Кәрим

Түбәндәге сүрәләрне укытучы балаларга укый, балалар укытучы артыннан кабатлыйлар һәм ятлыйлар:

- Әл-Мәгүн.
- Кураеш.
- Әл-Фил.
- Әл-Һүмәзәһ.

**Төп әдәбият:**

1. Һәфтияк шәриф. – Казан, 2012. – 152 бит.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Коръән Шәриф (Казан басмасы).

## 5. Фикыһ

Намазның мөфәсидләре, ягъни намазны боза торган эшләре.

Ирләр, сабыйлар, хатынлар бер имамга оесалар сафларга басу рәвешләре.

**Саум (ураза) китабы.**

Ураза тотуның фарыз икәнлеге. Ураза тотуга ният кылу. Сәхәр тору, ифтар кылу. Уразалы кешегә сөннәт булган эшләр. Уразалы вакытында мәкруһ булган эшләр. Уразаны бозучы эшләр. Кемгә ураза тоту фарыз түгел.

**Төп әдәбият:**

1. Ислам дине нигезләре – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2016.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Ә.Максуди. Гыйбадәте исламия. – Казан: «Матбугат йорты» нәшрияты, 2012.

## 6. Ислам тарихы

**Пәйгамбәрләр тарихы:** Ильяс пәйгамбәр гәләйһис-сәләм кыйссасы. Зәкәрия пәйгамбәр гәләйһис-сәләм кыйссасы. Яхъя пәйгамбәр гәләйһис-сәләм кыйссасы.

**Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в.с. нең тормышыннан:** Тәбүк вакыйгасы. Хушлашу хаҗы. Рәсүлүллаһ с.г.в.с. нең вафаты. Рәсүлүллаһ с.г.в.с. нең сыйфатлары. Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в.с. нең хатыннары.

**Татар халкының ислам тарихы:** Рус империясе чорында татарларда Ислам дине. Татар-мөселман галимнәре – Г.Курсави, Г.Утыз-Имәни, Ш.Мәрҗани.

**Төп әдәбият:**

1. Вәлиуллин К.Х. Ислам тәрбиясе. 1-4 сыйныфлар өчен дәреслек. — Казан: Идел-Пресс, 2016 - 256 б.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Бикбулат С. Хәзрәти Мөхәммәд. – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2014.
2. Фәхреддин Р. Мөхәммәд. – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2015.
3. Ислам дине нигезләре – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2016.

# Бишенче ел (6 яшьлекләр)

## 1. Гакыйдә

**Аллаһы Тәгаләгә иман.** Аллаһы Тәгаләгә шөкер итү. Аллаһы Тәгаләдән курку. Аллаһ һич беркемгә дә һәм һич бернәрсәгә дә охшамаган. Аллаһ бөтен нәрсәне Белүче. Аллаһ бөтен нәрсәне Күрүче. Аллаһ безнең өчен бу Галәмне һәм барча нәрсәләрне Бар итте. Аллаһ Мәрхәмәтле һәм Шәфкатьле. Безне туры юлга күндерү өчен пәйгамбәрләр җибәргән.

Аллаһы Тәгаләнең исемнәре: Әл-Мүмиитү, әл-Хәйү, әл-Кайюмү, әл-Вәәҗидү, әл-Мәәҗидү, әл-Вәәхидү, әл-Әхәдү, әс-Самәдү, әл-Каадиру, әл-Мүктәдиру, әл-Мүкаддимү, әл-Мүәххыру, әл-Әүвәлү, әл-Әәхыру, әз-Зааһиру.

Аллаһы Тәгаләнең сыйфатлары: I. Зәтия (Аллаһы Тәгаләнең Затына кагылышлы булган) сыйфатлары – 1) Әл-Вуҗүд; 2) Әл-Кыдәмү; 3) Әл-Бәка’ү; 4) Әл-Вәхдәнийятү; 5) Әл-Мүхаләфәтү лил-хәвәдис; 6) Әл-Кыямү би-нәфсиһи. II. Сүбүтия (Аллаһы Тәгаләнең Тиеш булучы) сыйфатлары – 1) Әл-Хәятү; 2) Әл-Гилмү; 3) Әс-Сәмгү; 4) Әл-Бәсару; 5) Әл-Кудратү; 6) Әл-Ирадәтү; 7) Әл-Кәләмү; 8) Әт-Тәквин.

**Ахыр заманга һәм Кыямәт көненә иман китерү.** Һәрбер кеше кайчан да булса бу дөньядан китәчәк, башкача әйткәндә үләчәк. Аннан соң икенче тормыш – Ахирәт тормышы башлана. Үлгән кеше кабергә күмелгәннән соң аның янына Мүнкәр һәм Нәкир исемле ике фәрештә килә. Бер заман шушы дөньяда яшәгән кешеләр һәм хайваннар үлеп һәм дөнья нәрсәләренең һәрберсе һәлак булып бетәчәкләр. Бу заманга Ахыр заман диелер. Кыямәт көненең кече галәмәтләре. Кыямәт көненең зур галәмәтләре. Каберләрдән кубарылу. Җәннәт. Җәһәннәм.

**Төп әдәбият:**

1. Вәлиуллин К.Х. Ислам тәрбиясе. 1-4 сыйныфлар өчен дәреслек. — Казан: Идел-Пресс, 2016 - 256 б.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Әдһәмов Г. Гакыйдә (Иман нигезләре). Уку әсбабы. Казан: Хузур, 2014. – 160 б.
2. Максуди Ә. Гыйбадәте исламия. — Казан: Идел-Пресс, 2013. — 112 б.

## 2. Әдәп-әхлак

**Мөселманның әхлакый вазифалары:**

Аллаһы Тәгаләгә карата вазифалар.

Пәйгамбәребез с.г.в.с. гә карата вазифалар.

Үзебезгә карата вазифалар.

Гаиләбезгә карата булган вазифалар.

Ватан һәм милләтебез каршындагы, бөтен кешелек алдындагы вазифалар.

**Ямьсез сыйфатлар:**

Гайбәт.

Ялган сөйләү.

Тәкәбберлек.

Исраф.

Көнчелек (хөсетлек).

Урлау.

**Төп әдәбият:**

1. Вәлиуллин К.Х. Ислам тәрбиясе. 1-4 сыйныфлар өчен дәреслек. — Казан: Идел-Пресс, 2016 - 256 б.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Аль-Газали Абу Хамид. Адабы. Казань: Идел-Пресс, 2013.
2. Балаларга үгет-нәсыйхәт. Яңартылган икенче басма. — Казан: «Дом печати», 2002. — 175 б.
3. Вәлиуллин К.Х. Әхлак. Мәчетләр каршындагы өч еллык курслар өчен дәреслек. Казан: «Казан Нуры» каршындагы «Шамил» мәдрәсәсе, 2015/1437. – 56 б.
4. Фазлыев Җ. Иманлы бала. Тәрбия турында. — Казан: «Идел-пресс» басмаханәсе, 2003. — 144 бит.
5. Фазлыев Җ. Локман Хәким нәсыйхәтләре. Казан: Хузур, 2014.
6. Ислам дине нигезләре – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2016.

## 3. Гарәп хәрефләре һәм тәҗвид

Мәдле хәрефләр.

Тәшдидле хәрефләр.

Тәнвинле хәрефләр.

Тәнвинле тәшдид.

Әлиф һәм һәмзә.

Тә мәрбута.

Язылмаса да укыла торган хәрефләр: әлиф мүкаддәра, « ى» (яй) мүкаддәра, « و » (вау) мүкаддәра.

Әлиф кебек укыла торган хәрефләр: яй әлифияһ, вау әлифияһ.

Язылса да укылмый торган хәрефләр.

Васл (кушу) кагыйдәсе.

Вакыф (туктау) кагыйдәсе.
Мәд (сузу) кагыйдәсе.
Идгам. Иклаб.
Гарәп хәрефләренең исемнәре.
Мүкаттагәт Куръәнияһ.
Күнегүләр һәм текстларны уку.

**Төп әдәбият:**

1. Әхмәдһади Максуди. Мүгаллим сәни. – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2015.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Вәлиуллин К. Гарәпчә язу. 1 нче һәм 2 нче өлеше. – Казан: «Иман» нәшрияты, 1996.
2. Курамшин Р.И. Башлангыч мәдрәсәләр һәм мәчетләр каршындагы курслар өчен тәҗвид дәреслеге. – Казан: “Хузур” нәшрияты, 2016.

## 4. Коръән Кәрим

Түбәндәге сүрәләрне укытучы балаларга укый, балалар укытучы артыннан кабатлыйлар һәм ятлыйлар:

- Әт-Тәкәссүр.
- Әл-Каригәһ.
- Әл-Гәдият.
- Әз-Зәлзәләһ.

**Төп әдәбият:**

1. Һәфтияк шәриф. – Казан, 2012. – 152 бит.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Коръән Шәриф (Казан басмасы).

## 5. Фикыһ

**Зәкят китабы.**

Зәкятнең аңлатмасы. Кемгә зәкят бирү фарыз була. Нәрсәдән зәкят бирелми. Алтын һәм көмештән зәкят бирү. Сәүдәдән зәкят бирү. Хайваннардан зәкят бирү. Уңыштан зәкят (гошер) бирү. Зәкят бирелә торган кешеләр. Фитра садәкасы. Садәка.

**Хаҗ китабы.**

Аңлатмасы. Хаҗ кылу кемгә фарыз булуы. Әл-Ихрам. Мәккәи Мөкәррәмгә бару. Тәваф кылу. Сәгыя кылу. Мина. Гарәфәт тавы. Мөздәлифә. Минада таш ату.

**Төп әдәбият:**

1. Ислам дине нигезләре – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2016.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Максуди Ә. Гыйбадәте исламия. – Казан: «Матбугат йорты» нәшрияты, 2012.

## 6. Ислам тарихы

**Пәйгамбәрләр тарихы:** Сөләйман пәйгамбәр гәләйһис-сәләм кыйссасы. Юнус пәйгамбәр гәләйһис-сәләм кыйссасы. Гайсә пәйгамбәр гәләйһис-сәләм кыйссасы.

**Ислам тарихы:** Тугры хәлифәләр Әбү Бәкер әс-Сиддыйк, Гомәр ибн Хаттаб әл-Фәрук, Госман бин Гаффан Зин-Нүрайн һәм Гали ибн Әбү Талиб Хәйдар.

**Татар халкының ислам тарихы:** XX гасыр башында татар халкының торышы. Җәдитчелек хәрәкәте. Олуг шәхесләр: Апанаевлар, Акчуриннар, Рәмиевләр, Хөсәеновлар, Г.Баруди, Р.Фәхретдин, М.Бигиев, Ә.Максуди һ.б. 1917 елгы инкыйлаб һәм татар халкының язмышы.

**Төп әдәбият:**

1. Вәлиуллин К.Х. Ислам тәрбиясе. 1-4 сыйныфлар өчен дәреслек. — Казан: Идел-Пресс, 2016 - 256 б.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Бикбулат С. Хәзрәти Мөхәммәд. – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2014.
2. Фәхреддин Р. Мөхәммәд. – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2015.
3. Ислам дине нигезләре – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2016.

# 7-10 ЯШЬЛЕК БАЛАЛАР ӨЧЕН ДИНИ ТӘРБИЯ ПРОГРАММАСЫ

## Беренче ел (7 яшьлекләр)

### 1. Гакыйдә

Ислам дине. Ислам диненең Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в.с. аркылы кешеләргә бирелгән Аллаһы Тәгаләнең дине булуы. Мөэмин һәм мөселман төшенчәләре.

Исламның биш нигезе: беренчесе - ике шәһадәт китерү; икенчесе - намаз уку; өченчесе - ураза тоту; дүртенчесе - зәкят бирү; бишенчесе - хаҗ кылу. Шәһадәтнең сүзләре һәм мәгънәсе. Шәһадәтне өйрәнү.

**Аллаһы Тәгаләгә иман.** Аллаһы Тәгалә барча нәрсәләрнең Бар итүчесе. Аллаһы Тәгалә барча нәрсәләрне, кешегә файда булсын өчен, Бар итүе. Аллаһы Тәгалә безгә биргән санаусыз нигъмәтләрне күрә белү һәм шулар өчен Аллаһы Тәгаләгә шөкерле булу. Аллаһы Тәгалә Ризыкландыручы. Аллаһы Тәгалә Рәхимле, Шәфкатьле.

Мөхәммәд с.г.в.с. не Аллаһы Тәгаләнең илчесе дип тануыбыз. Аның барча халыкларга динне өйрәтүе өчен җибәрелгәнлеге. Аның тормышын үзебезгә үрнәк итеп алырга тырышырга кирәклеге. Аның исемен әйткән вакытта яисә ишеткәндә «Салләллаһү галәйһи вә сәлләм» («Аңа Аллаһның сәламе булсын») дип хөрмәт белән искә алу кирәклеге.

*Радытү би-Лләһи Раббән вә бил-Исләми динән вә би-Мүхәммәдин Расүлән* (Аллаһның Патша булуыннан, Исламның дин булуыннан, Мөхәммәд с.г.в.с. нең Пәйгамбәр булуыннан разый булдым) дигән доганы өйрәтү.

Аллаһы Тәгаләнең исемнәре: Әр-Рахмәнү, әр-Рахиму, әл-Мәликү, әл-Куддүсү, әс-Сәләәмү, әл-Мүъминү, әл-Мүһәйминү, әл-Гәзизү, әл-Җәббәру, әл-Мүтәкаббиру, әл-Халику, әл-Бәриү, әл-Мүсаввиру, әл-Гаффәру, әл-Каһһәәру.

**Төп әдәбият:**

1. Вәлиуллин К.Х. Ислам тәрбиясе. 1-4 сыйныфлар өчен дәреслек. — Казан: Идел-Пресс, 2016 - 256 б.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Әдһәмов Г. Гакыйдә (Иман нигезләре). Уку әсбабы. Казан: Хузур, 2014. – 160 б.
2. Максуди Ә. Гыйбадәте исламия. — Казан: Идел-Пресс, 2013. — 112 б.
3. Ислам дине нигезләре – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2016.

### 2. Әдәп-әхлак

«Бисмилләһир-рахмәнир-рахим» сүзләрен әйтү: кайчан әйтелүе, әйтелүнең бәракәтләре һәм фәзыйләтләре.

Сәламләшү һәм саубуллашу әдәпләре. Мөселман бала, кардәше белән очрашканда, «Әс-сәламү галәйкүм вә рахмә-тул-лаһи вә бәракә-түһү», ә сәлам алучы «Вә галәйкүмү-с-сәлам вә рахмәтул-лаһи вә бәракәтүһү» дип сәламләшүе. Сәлам биргәндә бер-берләренең кулларын кысулары. Сәлам бирүнең тәртибе. Нинди хәлдә сәлам бирелмәс икәнлеге.

Ашау-эчү әдәпләре һәм догалары.

Уен әдәпләре.

Әтием һәм әнием. Әти-әнигә итагать итү, аларның икесен дә ярату, аларга хөрмәт күрсәтү һәм аларга чын күңелдән булышу кирәклеге. Әнинең өстенлеге. Әтинең өстенлеге. Әти-әнигә карата булган бурычлар.

Туганнарым һәм якыннарым. Мөселман бала тәрбияле булып, Аллаһы Тәгалә сөйгәннәрне эшләве һәм туганнарын, якыннарын яратуы. Туганнар ата-аналардан соң иң якын кешеләр булуы. Туганнарга һәм якыннарга карата булган бурычлар.

Кардәшләрем (дусларым) һәм күршеләрем. Мөселман бала тәрбияле булып, Аллаһы Тәгалә сөйгәннәрне эшләве, кардәшләрен (дусларын) һәм күршеләрен хөрмәт итүе. Кардәшләр (дуслар) ата-аналардан һәм туганнардан соң иң якын кешеләр булуы. Кардәшләремә (дусларыма) һәм күршеләремә карата бурычлар.

Тәннең, авыз-тешләрнең, чәчләрнең, кулларның һәм киемнең чисталыгы. Чисталык – иманның яртысы. Бәдрәфкә керү әдәпләре һәм догалары.

Белем алу әдәпләре. Дәрес алдыннан һәм дәрестән соң укыла торган догалар. «Рабби зидни гыйлмән нәфигән» догасын өйрәтү.

«Раббәнә әтинә фиддунья хәсәнәтән вә фи-л-әхырати хәсәнәтән вә кыйнә газәбән-нәр» догасын өйрәтү.

**Төп әдәбият:**

1. Вәлиуллин К.Х. Ислам тәрбиясе. 1-4 сыйныфлар өчен дәреслек. — Казан: Идел-Пресс, 2016 - 256 б.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Аль-Газали Абу Хамид. Адабы. Казань: Идел-Пресс, 2013.

2. Балаларга үгет-нәсыйхәт. Яңартылган икенче басма. — Казан: «Дом печати», 2002. — 175 б.

3. Вәлиуллин К.Х. Әхлак. Мәчетләр каршындагы өч еллык курслар өчен дәреслек. Казан: «Казан Нуры» каршындагы «Шамил» мәдрәсәсе, 2015/1437. – 56 б.

4. Фазлыев Җ. Иманлы бала. Тәрбия турында. — Казан: «Идел-пресс» басмаханәсе, 2003. — 144 бит.

5. Фазлыев Җ. Локман Хәким нәсыйхәтләре. Казан: Хузур, 2014.

6. Ислам дине нигезләре – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2016.

### 3. Гарәп хәрефләре һәм тәҗвид

Гарәп язуының үзенчәлекләре, өйрәнүнең максаты хакында гомуми белешмә бирү.

Әлифбаны уку.

Өс хәрәкә (фәтхә), ас хәрәкә (кәсрә) һәм өтер хәрәкә (даммә).

" ا " хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"ر " хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"ز " хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"م" хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"ت" хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"ن" хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"ي " хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"ب" хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"ك" хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"ل" хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"و" хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

" ه " хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"ف" хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"ق" хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"ش" хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"س" хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"ث" хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"ص" хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"ط" хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"ج" хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"خ" хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"ح" хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"غ" хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"ع" хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"د" хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"ض" хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"ذ" хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

"ظ" хәрефен өйрәнү һәм күнегүләр уку.

Мәдле хәрефләр.

Тәшдидле хәрефләр.
Тәнвинле хәрефләр.
Тәнвинле тәшдид.
Әлиф һәм һәмзә.
Тә мәрбута.
Язылмаса да укыла торган хәрефләр: әлиф мүкаддәра, « ى» (яй) мүкаддәра, « و » (вау) мүкаддәра.
Әлиф кебек укыла торган хәрефләр: яй әлифияһ, вау әлифияһ.
Язылса да укылмый торган хәрефләр.
Васл (кушу) кагыйдәсе.
Вакыф (туктау) кагыйдәсе.
Мәд (сузу) кагыйдәсе.
Идгам. Иклаб.
Гарәп хәрефләренең исемнәре.
Мүкаттагәт Куръәнияһ.
Күнегүләр һәм текстларны уку.

**Төп әдәбият:**

1. Максуди Ә. Мүгаллим сәни. – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2015.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Вәлиуллин К. Гарәпчә язу. 1 нче һәм 2 нче өлеше. – Казан: «Иман» нәшрияты, 1996.
2. Курамшин Р.И. Башлангыч мәдрәсәләр һәм мәчетләр каршындагы курслар өчен тәҗвид дәреслеге. – Казан: “Хузур” нәшрияты, 2016.

## 4. Коръән Кәрим

Коръән Кәрим Аллаһы Тәгалә тарафыннан Җәбраил фәрештә (Аңа Аллаһының сәламе булсын) аркылы Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в.с. гә 23 ел дәвамында гарәп телендә иңдерелүе. Коръән Кәримдә булган һәр сүз Аллаһы Тәгаләнең мөбәрак сүзләре булуы. Мөселманнар каршында аннан да кадерле һәм газиз Китап юклыгы.

Коръән Кәримгә карата булган әдәпләр.

Түбәндәге сүрәләрне тәҗвид кагыйдәләре белән дөрес уку, гомум тәфсире белән танышу һәм ятлау:

- Әл-Фәтихә.
- Әл-Ихлас.
- Әл-Фәләк.
- Ән-Нәс.
- Әл-Гаср.

**Төп әдәбият:**

1. Һәфтияк шәриф. – Казан, 2012. – 152 бит.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Вәлиуллин К.Х. Ислам тәрбиясе. 1-4 сыйныфлар өчен дәреслек. — Казан: Идел-Пресс, 2016 - 256 б.
2. Коръән Кәрим китабы (тәфсире һәм укылышы белән). — Казан: «Иман» нәшр., 2009. — 1172 б.
3. Коръән Шәриф (Казан басмасы).

## 5. Фикыһ

Намаз – Ислам дине нигезләренең икенчесе. Намаз укыячак кешенең тәне, киеме һәм урыны чиста булуы. Тәһарәтне алу рәвеше. Намаз ул – Аллаһы Тәгаләгә мәгълүм рәвештә күңел һәм тән белән гыйбадәт итү. Һәрбер мөселман кешегә көненә биш вакыт намаз уку тиеш: иртәнге намаз, өйлә, икенде, ахшам, ястү. Намаз уку рәвешләре. Азан сүзләре, азанны тыңлау әдәпләре.

Ислам дине нигезләренең өченчесе – һәр елда бер мәртәбә малдан зәкят бирү. Зәкят кем тарафыннан һәм кемнәргә бирелүе. Зәкят малы акчадан, алтыннан, көмештән, хайваннардан, уңыштан (җиләк-җимешләрдән) бирелүе. Сәдака - кешенең үз теләге белән бирелә торган хәер икәнлеге.

Ислам дине нигезләренең дүртенчесе – Рамазан аенда ураза тоту. Ураза нинди рәвештә тотылуы, тотылу вакыты. Рамазан аенда Коръән уку, тәравих намазларын уку, сәдакалар өләшү һәм башка изгелекләр эшләү бик саваплы булуы.

Ислам дине нигезләренең бишенчесе – гомерендә бер мәртәбә Мәккә шәһәренә барып, Хаҗ кылу. Хаҗ кылу кемгә фарыз булуы, ә кемгә фарыз булмавы. Хаҗ кылуның шартлары. Хаҗ гамәлләре, Мәккәи Мөкәррәмәдә һәм аның тирәсендә, һиҗри ел буенча Зөлхиҗҗә аеның 8-12 көннәрендә башкарылуы.

**Төп әдәбият:**

1. Вәлиуллин К.Х. Ислам тәрбиясе. 1-4 сыйныфлар өчен дәреслек. — Казан: Идел-Пресс, 2016 - 256 б.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Максуди Ә. Гыйбадәте исламия. – Казан: «Матбугат йорты» нәшрияты, 2012.
2. Ислам дине нигезләре – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2016.

## 6. Ислам тарихы

**Пәйгамбәрләр тарихы:** Адәм пәйгамбәр гәләйһис-сәләм кыйссасы. Нух пәйгамбәр гәләйһис-сәләм кыйссасы.

**Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в.с. нең тормышыннан:** Мөхәммәд с.г.в.с. нең гаиләсе; Фил вакыйгасы; Мөхәммәд с.г.в.с. нең балачагы; Мөхәммәд с.г.в.с. нең Әбү Талибның тәрбиясендә булуы.

**Татар халкының ислам тарихы:** Төрки халыклар. Идел Болгары. Борынгы бабаларыбыз болгарларның Ислам динен кабул итүләре. Багдадтан Болгарга илчеләр килүе. Әхмәд ибн Фадланның юлъязмалары. Болгар иле. Болгар, Биләр, Сувар һ.б. шәһәрләр. Кол Гали һәм аның «Кыйссаи Юсуф» әсәре. Монгол явы.

**Төп әдәбият:**

1. Курамшин Р.И. Башлангыч мәдрәсәләр һәм мәчетләр каршындагы курслар өчен тәҗвид дәреслеге. – Казан: “Хузур” нәшрияты, 2016.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Вәлиуллин К. Тәҗвид кагыйдәләре (Коръән Кәримне дөрес уку кагыйдәләре). Правила таджвида (правила правильного чтения Священного Корана с переводом на русский язык). — Казан: Мөхәммәдия мәдрәсәсе, 2010/1429.

## 4. Коръән Кәрим

Коръән Кәримне уку һәм аның гыйлемен үзендә йөртүченең өстенлекләре.

Түбәндәге сүрәләрне тәҗвид кагыйдәләре белән дөрес уку, гомум тәфсире белән танышу һәм сүрәне ятлау:

- Әл-Кәүсәр.
- Әл-Кәфирун.
- Ән-Нәср.
- Әл-Мәсәд.
- Әл-Бәкара сүрәсенең 255 аяте («Аятел Көрси»).

**Төп әдәбият:**

1. Һәфтияк шәриф. – Казан, 2012. – 152 бит.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Вәлиуллин К.Х. Ислам тәрбиясе. 1-4 сыйныфлар өчен дәреслек. — Казан: Идел-Пресс, 2016 - 256 б.
2. Коръән Кәрим китабы (тәфсире һәм укылышы белән). — Казан: «Иман» нәшр., 2009. — 1172 б.
3. Коръән Шәриф (Казан басмасы).

## 5. Фикыһ

**Намаз китабы.**

Намазның фарызлыгы. Намаз укымаучыга Кыямәт көнендә нинди җәзалар бар. Мөселман кешесе көненә ничә намаз укырга тиеш, исемнәре, тагын нинди намазлар бар.

Намазларның вакытлары. Намаз укырга ярамый торган вакытлар.

Кыйбла нәрсә, кая, аны ничек табарга, компас белән табу, сахрада яисә урманда Кыйбланы табу.

Ният.

Азан һәм камәт нинди гамәлләргә керә. Азанны малайларга әйттерү. Камәтнең азаннан булган аермалары. Азанның мөстәхәбләре. Азан догасы (ятлаттыру).

Намаз эчендә һәм соңында укылачак зикерләр: сәнә, әгүзе, сүрәи Фатиха, кыска сүрәләр, рукүгъ тәсбихе, тәсмиг, тәхмид, сәҗдә тәсбихе, тәшәһһөд, салават, дога аяте, сәлам, сәлам догасы.

Күнүт догасы (нинди намазда укыла, шушы доганы ятлау).

Ике рәкәгатьле намаз; өч рәкәгатьле намаз; дүрт рәкәгатьле намаз.

Хатынлар намазы (хатынларның ирләр намазыннан 8 җирдәге аермасы).

Намаздан соң укылачак тәсбих һәм догалар.

Зәгыйфь кешенең намазы.

**Төп әдәбият:**

1. Вәлиуллин К.Х. Ислам тәрбиясе. 1-4 сыйныфлар өчен дәреслек. — Казан: Идел-Пресс, 2016 - 256 б.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Ә.Максуди. Гыйбадәте исламия. – Казан: «Матбугат йорты» нәшрияты, 2012.
2. Ислам дине нигезләре – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2016.

## 6. Ислам тарихы

**Пәйгамбәрләр тарихы.**

**Һүд галәйһиссәлам.** Гад кавемененең озын буйлы һәм көчле халык булуы, шуның белән тәкәбберләнүләре. Аларга пәйгамбәр буларак Һүд галәйһиссәламнең җибәрелүе. Һүд галәйһиссәламнең үзенең кавемен ялгыз Бер Аллаһка гыйбадәт итүгә чакыруы, потларга табынудан кисәтүе. Халкының аны мыскыл итүе, чакыруына колак салмавы. Аллаһы Тәгалә тарафыннан аларга газап җибәрелүе: корылыкның булуы, салкынның килүе. Җиде көн һәм сигез төн дәвамында бик көчле җилнең булуы. Гад кавеменең һәлак булуы.

**Салих галәйһиссәлам.** Самуд кавымының Салих пәйгамбәрнең, Аллаһы Тәгаләнең диненә, чакыруын инкяр итүләре. Салих пәйгамбәрнең могҗизасы. Изге дөянең вафаты. Самудит кавымының һәлак булуы: сәбәпләре һәм шаукымы.

**Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в.с. нең тормышыннан.**

Мөхәммәд с.г.в.с. гә вәхи килүе. Вәхинең төрләре. Хатыны Хәдичә радый Аллаһү ганһә белән Варака янына барулары. Вәхинең туктап торуы. Вәхинең яңадан башлануы. Яшерен дәгъвәт. Беренче мөселманнар.

Ачык дәгъвәт. Сафа тавында курайшләрне Исламга чакыру. Мөшрикләрнең Ислам таралуга каршы көрәше (Әбү Талип янына барулары, мөселманнарны мәсхәрәләүләре, җәзалаулары, могҗиза күрсәтүне сораулары, Коръәннән үзләренә охшамаган сүзләрне алуны сораулары һ.б). Хәмзәнең Ислам динен кабул итүе.

Мөселманнарның Эфиопиягә һиҗрәте. Мөшрикләрнең мөселманнарга бойкоты. Гомәр ибн Хаттабның Исламны кабул итүе. Бойкотның бетерелүе.

**Татар халкының ислам тарихы.** Алтын Урда (XIII—XIV гасырлар). Алтын Урданың биләгән территориясе. Алты Урданың шәһәрләре. Алтын Урда ханнары. Алтын Урданың мәдәнияте. Алтын Урданың таркалуы.

**Төп әдәбият:**

1. Вәлиуллин К.Х. Ислам тәрбиясе. 1-4 сыйныфлар өчен дәреслек. — Казан: Идел-Пресс, 2016 - 256 б.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Бикбулат С. Хәзрәти Мөхәммәд. – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2014.
2. Фәхреддин Р. Мөхәммәд. – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2015.
3. Ислам дине нигезләре – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2016.

## <u>Өченче ел (13 яшьлекләр)</u>

### 1. Гакыйдә

Аллаһы Тәгаләнең исемнәре: Әл-Хабииру, әл-Хәлииму, әл-Гәзыыму, әл-Гафүүру, әш-Шәкүүру, әл-Гәлийү, әл-Кәбииру, әл-Хәфиизу, әл-Мүкиитү, әл-Хәсиибү, әл-Җәлиилү, әл-Кәриимү, әр-Ракыыбү, әл-Мүҗиибү, әл-Вәәсигү.

Аллаһы Тәгаләнең сыйфатлары: I. Зәтия (Аллаһы Тәгаләнең Затына кагылышлы булган) сыйфатлары – 1) Әл-Вуҗүд; 2) Әл-Кыдәмү; 3) Әл-Бәка'ү; 4) Әл-Вәхдәнийятү; 5) Әл-Мүхаләфәтү лил-хәвәдис; 6) Әл-Кыямү би-нәфсиһи. II. Сүбүтия (Аллаһы Тәгаләнең Тиеш булучы) сыйфатлары – 1) Әл-Хәятү; 2) Әл-Гилмү; 3) Әс-Сәмгү; 4) Әл-Бәсару; 5) Әл-Кудратү; 6) Әл-Ирадәтү; 7) Әл-Кәләмү; 8) Әт-Тәквин.

**Китапларга иман китерү.** Аллаһы Тәгалә дин хөкемнәрен аңлатып, пәйгамбәрләренә Китаплар иңдергән. Аларда Аллаһның кешеләргә әмер иткән һәм тыйган нәрсәләре язылган. Пәйгамбәрләр шул Китаплардагы хөкемнәр белән халыкларын иманга һәм изге гамәлләр кылырга өндәгәннәр.

Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә иңдерелгән биш Китапның исемнәрен китерә: 1. Сәхифәләр (Ибраһим гәләйһис-сәләмгә иңдерелде); 2. Зәбур (Дауд гәләйһис-сәләмгә иңдерелде); 3. Тәүрат (Муса гәләйһис-сәләмгә иңдерелде); 4. Инҗил (Гайсә гәләйһис-сәләмгә иңдерелде); 5. Коръән Кәрим (Мөхәммәд с.г.в.с. гә иңдерелде).

Коръән Кәримне Аллаһы Тәгалә Рәсүлебез Мөхәммәд с.г.в.с. гә 23 ел дәвамында Җәбраил г.с. фәрештә аркылы иңдергән. Ул Пәйгамбәребез с.г.в.с. нең могҗизасы була. Аллаһы Тәгалә аны гарәп телендә иңдергән. Коръән Кәрим Аллаһы Тәгалә тарафыннан иңдерелгән ахыргы Китап булып

санала. Коръән Кәримнең үзенчәлекләре. Коръән Кәримнең башка илаһи Китаплардан булган аермалары.

**Төп әдәбият:**

1. Вәлиуллин К.Х. Ислам тәрбиясе. 1-4 сыйныфлар өчен дәреслек. — Казан: Идел-Пресс, 2016 - 256 б.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Әдһәмов Г. Гакыйдә (Иман нигезләре). Уку әсбабы. Казан: Хузур, 2014. – 160 б.
2. Максуди Ә. Гыйбадәте исламия. — Казан: Идел-Пресс, 2013. — 112 б.
3. Ислам дине нигезләре – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2016.

## 2. Әдәп-әхлак

**Мөселманның әхлакый вазифалары:**

Аллаһы Тәгаләгә карата вазифалар.

Пәйгамбәребез с.г.в.с. гә карата вазифалар.

Үзебезгә карата вазифалар.

Гаиләбезгә карата булган вазифалар.

Ватан һәм милләтебез каршындагы, бөтен кешелек алдындагы вазифалар.

**Күркәм холыклар:**

Тырышлык.

Сабырлык.

Әманәт. Гомәр әл-Фәрук кыйссасы.

**Мөселман читләшергә тиеш ямьсез сыйфатлар:**

Исраф.

Көнчелек (хөсетлек).

Урлау.

**Ислам әдәпләре һәм догалары:**

Берәр зарар һәм зыян килсә укыла торган дога.

Кием әдәпләре һәм догалары.

Төчкерү әдәпләре һәм әйтелә торган догалары.

**Төп әдәбият:**

1. Вәлиуллин К.Х. Ислам тәрбиясе. 1-4 сыйныфлар өчен дәреслек. — Казан: Идел-Пресс, 2016 - 256 б.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Аль-Газали Абу Хамид. Адабы. Казань: Идел-Пресс, 2013.
2. Балаларга үгет-нәсыйхәт. Яңартылган икенче басма. — Казан: «Дом печати», 2002. — 175 б.
3. Вәлиуллин К.Х. Әхлак. Мәчетләр каршындагы өч еллык курслар өчен дәреслек. Казан: «Казан Нуры» каршындагы «Шамил» мәдрәсәсе, 2015/1437. – 56 б.

4. Фазлыев Җ. Иманлы бала. Тәрбия турында. — Казан: «Идел-пресс» басмаханәсе, 2003. — 144 бит.

5. Фазлыев Җ. Локман Хәким нәсыйхәтләре. Казан: Хузур, 2014.

6. Ислам дине нигезләре – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2016.

### 3. Тәҗвид

Идгам кагыйдәләре: Идгам мисләин; Идгам мүтәҗәнисәин; Идгәм мүтәкарибәин. Кагыйдәләрнең аңлатмалары. Бу кагыйдәләр буенча хәрефләрнең укылышы.

Мәд кагыйдәләре: Мәднең аңлатмасы; Мәд хәрефләре; Сәбәби мәд; Мәд табигый; Мәд моттәсыйл; Мәд монфасыйл; Мәд ләзем; Мәд гарыйз; Мәд лин. Кагыйдәләрнең аңлатмалары. Бу кагыйдәләр буенча хәрефләрнең укылышы. Мукаттагаһ хәрефләре.

Вакыф галәмәтләре. Ирексездән туктау. Туктаганда сүзнең ахыры үзгәрү.

Калькалә кагыйдәсе. Калькалә хәрефләре һәм аларның укылышы.

Сәктә кагыйдәсенең аңлатмасы. Кагыйдәне Коръән укыганда куллану рәвеше.

Тәксир тәнвин кагыйдәсенең аңлатмасы. Бу кагыйдә буенча хәрефләрнең укылышы.

**Төп әдәбият:**

1. Курамшин Р.И. Башлангыч мәдрәсәләр һәм мәчетләр каршындагы курслар өчен тәҗвид дәреслеге. – Казан: “Хузур” нәшрияты, 2016.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Вәлиуллин К. Тәҗвид кагыйдәләре (Коръән Кәримне дөрес уку кагыйдәләре). Правила таджвида (правила правильного чтения Священного Корана с переводом на русский язык). — Казан: Мөхәммәдия мәдрәсәсе, 2010/1429.

### 4. Коръән Кәрим

Коръән Кәрим турында сорау-җавап.

Түбәндәге сүрәләрне тәҗвид кагыйдәләре белән дөрес уку, гомум тәфсире белән танышу һәм ятлау:

- Әл-Бәкара сүрәсенең 1-5 аятләре (Әлифләммим).
- Әл-Мәгун сүрәсе.
- Курайш сүрәсе.
- Әл-Фил сүрәсе.
- Әл-Һүмәзәһ сүрәсе.

**Төп әдәбият:**

1. Һәфтияк шәриф. – Казан, 2012. – 152 бит.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Вәлиуллин К.Х. Ислам тәрбиясе. 1-4 сыйныфлар өчен дәреслек. — Казан: Идел-Пресс, 2016 - 256 б.

2. Коръән Кәрим китабы (тәфсире һәм укылышы белән). — Казан: «Иман» нәшр., 2009. — 1172 б.

3. Коръән Шәриф (Казан басмасы).

### 5. Фикыһ

Мөселман календаре. Мөселман бәйрәмнәре.

**Намаз китабы.** Намазның шартлары (тышындагы фарызлары. Рөкенләре (эчендәге фарызлары). Намазның ваҗиблары. Намазның сөннәтләре. Намазның мөстәхәбләре. Намазның мәкруһлары. Намазның мөфәсидләре, ягъни намазны боза торган эшләре. Намазда мөбах булган эшләр.

**Җәмәгать.** Намазны җәмәгать белән укуның өстенлекләре. Имам белән моктәди намаз укуның рәвеше. Моктәди бер генә кеше булганда, ике кеше яисә артык булсалар имам белән янәшә басу рәвешләре. Ирләр, сабыйлар, хатынлар бер имамга оесалар сафларга басу рәвешләре. Берничә кеше арасында намазны җәмәгать белән уку өчен имамны сайлау рәвеше. Кемгә имам булу мәкруһ.

Имам намазны укый башлагач килеп җитешкән кешенең хөкеме. Мөдрик һәм мәсбүкнең аңлатмасы. Мәсбукның намазны тәмамлау рәвеше.

**Мәсҗид вә җамигъ.** Мәчеткә керү алдыннан һәм чыкканда дога; мәчеттә үзеңне тоту әдәбе; иртә намазын уку өчен мәчеткә кергәндә имам фарызын укыса нинди хөкем бар; өйлә намазын уку өчен мәчеткә кергәндә имам фарызын укыса нинди хөкем бар; хатынларның намазны мәчеткә барып уку хөкеме.

**Намазның казасы.** Намазны казага калдыру мәсьәләсе. Иртәнге намаз калдырылса. Башка намазлар калдырылса.

**Сәҗдәи сәһү.** Бер кеше намазның бер фарызын, ваҗибын калдырса. Сәҗдәи сәһүне эшләү рәвеше: ялгыз укучыга, имамга.

**Намазда саташу.** Дүрт рәкәгатьле намазда ялгышып, әүвәлге кагъдәгә утырмыйча, кыямга тора башласа. Дүрт рәкәгатьле намазда ялгышып 5-че рәкәгатьне укый башласа. Намаз эчендә ничә рәкәгать укыганын онытса. Бу хәл 2-3 мәртәбә кабатланса. Дүрт рәкәгатьле намазда, ике рәкәгать укыгач, ялгышып сәлам бирсә.

**Төп әдәбият:**

1. Вәлиуллин К.Х. Ислам тәрбиясе. 1-4 сыйныфлар өчен дәреслек. — Казан: Идел-Пресс, 2016 - 256 б.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Максуди Ә. Гыйбадәте исламия. – Казан: «Матбугат йорты» нәшрияты, 2012.
2. Ислам дине нигезләре – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2016.

## 6. Ислам тарихы

**Пәйгамбәрләр тарихы.**

**Ибраһим галәйһиссәләм һәм Исмәгыйл гәләйһиссәләм.** Аның хакыйкать эзләве. Мәҗүсиләр белән бәхәсләре. Сыннарны ватуы. Учакка ыргытылуы һәм аннан зарарсыз чыгуы. Нәмруд патшаның манара төзүе.Ибраһим галзйһиссәләмнең Палестинага күчүе. Улы Исмәгыйлнең тууы һәм аны әнисе Хәҗәр белән Мәккә үзәнлегендә калдыруы. Корбан вакыйгасе. Икенче улы Исхакның тууы. Улы Исмәгыйл белән Кәгъбәтуллаһны төзүе. Догалары. Аның нәселеннән күп пәйгамбәрләр килүе.

**Лут галәйһиссәлам.** Лут пәйгамбәрнең Аллаһның диненә чакыруына карамастан, халкының игтибарсызлык күрсәтүе. Лут пәйгамбәр янына фәрештәләрнең килүе. Аллаһы Тәгалә тарафыннан Лут пәйгамбәрнең кавемен һәлак итүе.

**Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в.с. нең тормышыннан.**

Мөхәммәд галәйһиссәләмнең кайгы елы. Сәүдәткә һәм Гайшәгә өйләнүе. Таифка дәгъвәт белән баруы. Исра һәм Мигъраҗ вакыйгасы. Гакабә килешүләре.

Мәккәдән Мәдинәгә һиҗрәт. Кубада беренче мәчет төзү. Мәдинә халкының Мөхәммәд галәйһиссәләмне каршы алуы. Мүһәҗирләр һәм ансарларны туганлаштыру. Мәдинәдә мәчет төзелү. Беренче азан әйтелү.

Кыйбла үзгәрү. Бәдер сугышы. Бәнү Кайнука кабиләсе белән сугыш. Үхүд сугышы һәм аның нәтиҗәләре. Раҗига көне. Мәгунәһ коесы. Бәнү Надыйр кавемен куу. Бәнү мүстталәкъ кабиләсе белән сугыш. Ялган хәбәр. Хандак сугышы. Сугыш алдыннан булган могҗиза (мөселманнар ризыгының бәракәте арту). Бәни Курайза кабиләсе белән сугыш.

Худайбия килешүе. Хәйбәр сугышы. Калган мөселманнарның Эфиопиядән кайтуы. Башка илләрнең патшаларына хатлар. Гумрәне каза кылу. Муэтә сугышы. Мәккәне җиңү.

**Татар халкының ислам тарихы.** Казан ханлыгының барлыкка килүе. Казан ханлыгының биләп торган мәйданы. Казан ханлыгының шәһәрләре. Казан ханлыгының руслар белән булган мөнәсәбәте. Казан ханнары. Сөембикәнең язмышы. Кол Шәриф, Мөхәммәдьяр әсәрләре. Казан каласының руслар тарафыннан яулап алынуы. Казан каласының истәлек урыннары.

**Төп әдәбият:**

1. Вәлиуллин К.Х. Ислам тәрбиясе. 1-4 сыйныфлар өчен дәреслек. — Казан: Идел-Пресс, 2016 - 256 б.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Бикбулат С. Хәзрәти Мөхәммәд. – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2014.
2. Фәхреддин Р. Мөхәммәд. – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2015.
3. Ислам дине нигезләре – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2016.

# Дүртенче ел (14 яшьлекләр)

## 1. Гакыйдә

Аллаһы Тәгаләнең исемнәре: Әл-Хәкииму, әл-Вәәдүүдү, әл-Мәҗиидү, әл-Бәәгисү, әш-Шәһиидү, әл-Хәкку, әл-Вәкиилү, әл-Кавийү, әл-Мәтиину, әл-Вәлийү, әл-Хәмиидү, әл-Мүхсы, әл-Мүбдиү, әл-Мүгиидү, әл-Мүхии.

**Ахыр заманга һәм Кыямәт көненә иман.** Ахирәт көненә иман китерүнең аңлатмасы. Үлем – бу дөньядан Ахыйрәт тормышына күчү ул. Кешенең үлемнән соң булачак халәте, дөньяда кылган гамәлләре белән бәйле булуы. Иманлы кешенең җаны җиңеллек белән чыгуы, имансыз кешенең җаны авырлык белән чыгуы. Кабердә сорау алыну. Иманлы һәм имансыз кешенең кабердәге хәле (нигъмәт яки газап). Үлем һәм кабердәге хәлләр белән бәйле Коръән Кәрим аятьләре һәм Пәйгамбәребез с.г.в.с. нең хәдис-шәрифләре.

Кыямәт көненең кече галәмәтләре. Кыямәт көненең зур галәмәтләре: Мәсих Дәҗҗәлнең чыгуы, Дәҗҗәлдән саклану чаралары; Гайсә г.с. нең икенче килүе; Яэҗүҗ һәм Мәэҗүҗ кавеменең чыгуы; Даббәнең чыгуы; Кояшның көнбатыштан чыгуы.

Ахыйрәт көненең башлануы: кояшның сүнүе, айның карангыга төшүе, күкнең гадәттән тыш хәрәкәтләнүе, йолдызларның сүнүе, тауларның урыннарыннан авышуы. Кабердән кубарылу (Бәгыс). Мәхшәр мәйданына җыелу. Җиде төр кешенең Аллаһы Тәгалә Көрсиенең күләгәсе астында булулары. Хисап ителү. Гамәл дәфтәрләренең бирелүе. Хисап ителгәндә кешеләрнең әгъзалары да шаһитлык бирүләре. Хауз кәүсәре. Мизаннарның куелуы. Сыйратны үтү. Җәннәт һәм андагы нигъмәтләр. Җәһәннәм һәм андагы газаплар. Кыямәт көне белән бәйле Коръән Кәрим аятьләре һәм Пәйгамбәребез с.г.в.с. нең хәдис-шәрифләре.

**Тәкъдиргә иман.** Тәкъдир – ул Аллаһы Тәгалә Галәмдәге булачак (бар итәчәк, яратачак, яралтачак) барлык нәрсәләрне әле бар иткәнче, алар белән булачак яхшысын да, яманын да Үзенең чиксез һәм мәңге булучы гыйлеме белән белеп, Ләүхелмәхфүзгә язып куйган һәм Аның Белеменә тәңгәл китерелеп шуларның бөтенесенең башкарылуы (барлыкка китерелүе).

Кешегә ирешә торган гамәлләр ике төрле булуы. Беренчесе – кешегә ихтыярсыз ирешә торганнары, ягъни бар гамәлләр дә мәҗбүри рәвештә була һәм кешенең ул гамәлләргә карата бернинди дә катнашы юк. Икенчесе – кеше үз ихтыяры һәм теләге белән башкарыла торган гамәлләр һәм шул сәбәпле кеше шушы гамәлләре хакында Кыямәт көнендә соралуы.

Аллаһы Тәгалә Үзенең Ирадасы, Кодрәте һәм Белеме белән, барча нәрсәләрнең Яратучысы буларак, яхшылыкны да һәм яманлыкны да Барлыкка китерүче. Яманлыкның килүе түбәндәге сәбәпләр белән бәйле булырга мөмкин: Беренчесе – яманлыкта яхшылык булырга мөмкин яисә яхшылыкта начарлык булырга мөмкин. Икенчесе – яманлык белән Аллаһы Тәгалә кешеләрне сынарга мөмкин. Өченчесе – яманлык белән Аллаһы Тәгалә кешеләрне гөнаһлардан һәм хаталардан чистартырга (пакъларга) мөмкин.

**Төп әдәбият:**

1. Вәлиуллин К.Х. Ислам тәрбиясе. 1-4 сыйныфлар өчен дәреслек. — Казан: Идел-Пресс, 2016 - 256 б.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Әдһәмов Г. Гакыйдә (Иман нигезләре). Уку әсбабы. Казан: Хузур, 2014. – 160 б.
2. Максуди Ә. Гыйбадәте исламия. — Казан: Идел-Пресс, 2013. — 112 б.
3. Ислам дине нигезләре – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2016.

## 2. Әдәп-әхлак

**Күркәм холыклар:**

Локман Хәкимнең улына әйткән нәсыйхәтләре.

Яхшы һәм начар сүз. Галимҗан Латыйп. Яхшы сүз, яман сүз.

Әти-әнигә хөрмәт.

**Мөселман читләшергә тиеш ямьсез сыйфатлар:**

Ифтира (яла ягу), бөһтан һәм сүз йөртү.

Кеше үтерү.

Исерткеч (хәмер) эчү.

Отышлы уеннар уйнау.

Зина кылу.

**Ислам әдәпләре һәм догалары:**

Йокы әдәпләре һәм укыла торган догалары.

Юл әдәпләре һәм догалары.

Мәчет әдәпләре һәм догалары.

**Төп әдәбият:**

1. Вәлиуллин К.Х. Ислам тәрбиясе. 1-4 сыйныфлар өчен дәреслек. — Казан: Идел-Пресс, 2016 - 256 б.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Аль-Газали Абу Хамид. Адабы. Казань: Идел-Пресс, 2013.
2. Балаларга үгет-нәсыйхәт. Яңартылган икенче басма. — Казан: «Дом печати», 2002. — 175 б.
3. Вәлиуллин К.Х. Әхлак. Мәчетләр каршындагы өч еллык курслар өчен дәреслек. Казан: «Казан Нуры» каршындагы «Шамил» мәдрәсәсе, 2015/1437. – 56 б.
4. Фазлыев Җ. Иманлы бала. Тәрбия турында. — Казан: «Идел-пресс» басмаханәсе, 2003. — 144 бит.
5. Фазлыев Җ. Локман Хәким нәсыйхәтләре. Казан: Хузур, 2014.
6. Ислам дине нигезләре – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2016.

## 3. Коръән Кәрим

Коръәннең иңдерелүе һәм бер мусхафка тупланыуы. Коръәнне бастыру тарихы. Коръәннең «Казан басмасы»ның тарихы. «Тәфсир» сүзенең аңлатмасы. Тәфсир фәненең Коръәнне аңлауда әһәмияте. Тәфсир фәненең кыскача тарихы.

Түбәндәге сүрәләрне тәҗвид кагыйдәләре белән дөрес уку, гомум тәфсире белән танышу һәм сүрәне ятлау:

- Әт-Тәкәсүр сүрәсе.
- Әл-Каригәһ сүрәсе.
- Әз-Зәлзәләһ сүрәсе.
- Әл-Кадер сүрәсе.
- Әт-Тин сүрәсе.

**Төп әдәбият:**

1. Һәфтияк шәриф. – Казан, 2012. – 152 бит.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Вәлиуллин К.Х. Ислам тәрбиясе. 1-4 сыйныфлар өчен дәреслек. — Казан: Идел-Пресс, 2016 - 256 б.
2. Коръән Кәрим китабы (тәфсире һәм укылышы белән). — Казан: «Иман» нәшр., 2009. — 1172 б.
3. Коръән Шәриф (Казан басмасы).

## 4. Фикыһ

**Сәҗдәи тиләвәт.**

**Мокыйм вә мөсафир.** Мокыйм һәм мөсафирның аңлатмасы. Кайчан кеше мөсафир дип исемләнә. Мөсафирның өч хөкеме.

**Башка намазлар.** Җомга намазы. Гайд намазлары. Тәравих намазы.

**Җәназа.** Үлем хәлендәге кеше, аңа карата булган әдәпләр. Кешенең вафат булуы. Вафат булган кешегә карата эшләнә торган гамәлләр (яткыру тәртибе, төн уздыру, кәфенлекне әзерләү һ.б.). Мәетне юу, мәеткә кәфенлек киертү (бу темалар гомум рәвештә аңлатыла). Җәназа намазы. Мәетне озату һәм кабергә күмү. Шәһид булып киткәннәр.

**Төп әдәбият:**

1. Ислам дине нигезләре – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2016.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Максуди Ә. Гыйбадәте исламия. – Казан: «Матбугат йорты» нәшрияты,

## 5. Ислам тарихы

**Пәйгамбәрләр тарихы.**

**Йосыф гәләйһиссәләм.** Йосыф гәләйһиссәләм хакында Корән

Кәримдә сөйләгәнлеге. Йосыф галәйһиссәләмнең төш күрүе. Абыйлары белән сахрага чыгуы һәм аны коеда калдырулары. Йосыфны үтеп баручы кәрван кешеләре тарафыннан алулары һәм сатып җибәрүләре. Аның патша сараенда хезмәт итүче бер затлы кешенең тәрбиясендә булуы һәм шул кешенең хатыны тарафыннан гөнаһ эшләүгә өндәлүе. Йосыфның төрмәгә эләгүе һәм анда булучы ике ир кешегә төш юравы. Патшага төш юравы. Мисыр дәүләтендә министр итеп билгеләнелүе. Абыйлары белән очрашуы һәм шуның белән бәйле вакыйгалар. Әтисе һәм туганнары белән кавышуы.

**Шугайб галәйһиссәлам.** Мадян халкының Шугайб пәйгамбәрнең Аллаһның диненә чакыруын инкяр итүләре. Мадян кавеменең һәлак ителүе. Иманлыларның коткарылуы.

**Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в.с. нең тормышыннан.** Хүнәйн сугышы. Трофейларны бүлү. Хәүәзин кабиләсенең Исламны кабул итүе. Тәбүк сугышы. Сугышка бармаучылар. Зарарлы мәчет. Сәкыйф кабиләсе вәкилләре һәм аларның Исламны кабул итүләре. Гарәп делегацияләренең бер-бер артлы Исламны кабул итүләре. Төрле якларга дәгъвәтчеләр җибәрү. Мөхәммәд галәйһиссәләмнең аларга нәсихәте.

Саубуллашу хаҗы һәм аның хөтбәсе. Мөхәммәд галәйһиссәләмнең авыруы һәм вафаты. Мөхәммәд с.г.в.с. нең сыйфатлары. Гаиләсе һәм балалары.

Мөхәммәд галәйһиссәләмнең Сөннәте, аның әһәмияте. Хәдисләр. Хәдисләрнең җыелуы. Хәдисләрнең төрләре. Хәдисләр җыентыклары. Кайбер хәдис үрнәкләре һәм аларның аңлатмалары («40 хәдис» китабыннан).

**Татар халкының ислам тарихы.** Касыйм ханлыгы тарихыннан. Кырым ханлыгы тарихыннан. Себер ханлыгы тарихыннан. Әстерхан ханлыгы тарихыннан. Олы Урда тарихыннан. Нугай Урдасы тарихыннан.

**Төп әдәбият:**

1. Вәлиуллин К.Х. Ислам тәрбиясе. 1-4 сыйныфлар өчен дәреслек. — Казан: Идел-Пресс, 2016 - 256 б.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Бикбулат С. Хәзрәти Мөхәммәд. – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2014.
2. Фәхреддин Р. Мөхәммәд. – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2015.
3. Ислам дине нигезләре – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2016.

# Бишенче ел (15 яшьлекләр)

## 1. Гакыйдә

Аллаһы Тәгаләнең исемнәре: Әл-Мүмиитү, Әл-Хәйү, Әл-Кайюмү, Әл-Вәәҗидү, Әл-Мәәҗидү, Әл-Вәәхидү, Әл-Әхәдү, Әс-Самәдү, Әл-Каадиру, Әл-Мүктәдиру, Әл-Мүкаддимү, Әл-Мүәххыру, Әл-Әүвәлү, Әл-Әәхыру, Әз-Зааһиру.

Ризыкның аңлатмасы. Мөселманга кәсеп итүнең тиешлеге. Ни өчен Аллаһы Тәгалә гадел Зат була торып, кайбер кешегә ризыкны аз бирә (ягъни аны фәкыйрь итә), ә кайберләренә ризыкны күп бирә (ягъни аларны бай итә)?

«Әҗәл» - кешегә һәм башка мәхлукатларга Аллаһы Тәгалә тарафыннан язылып карар кылынган гомеренең бетүе икәнлеге. Һәрбер кешенең гомере (яшәячәк вакыты) Аллаһы Тәгалә тарафыннан билгеләнгән һәм әгәр аның гомере бетсә, ягъни әҗәле җиткән булса, ул бер секундка иртәрәк тә килмәс һәм кичектерелмәс тә. Гомерне озынайту хакындагы хәдиснең мәгънәсе.

Аллаһы Тәгаләгә тәвәккәл кылу – ул күңеле белән Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать итү, Аның ярдәменә таяну, теләгенә ирешүен сораган вакытында, Аллаһы Тәгаләдән авырлык һәм киртәләрне этәрүен, булышлык һәм ярдәм белән ныгытуын сорау. Шул ук вакытта, Аллаһы Тәгалә аңа ярдәм итәр һәм ул сораган нәрсә башкарылыр икәненә катгый ышана, әгәр сораган нәрсәсе аның өчен хәерле булса.

Дин хөкемнәренең төрләре. Аллаһы Тәгалә тарафыннан дин хөкемнәрен иңдерүнең максатлары. Әл-Мисак.

Фитри иман. Кешенең табигый табыну ихтыяҗының сәбәпләре. Иман китерүнең төрләре. Ислам гакыйдәсе кеше алдында куя торган максатлары.

Кешенең бу дөньяда яшәвенең максаты. Аллаһы Тәгаләгә буйсыну, гыйбадәт кылу. Савап һәм гөнаһ. Хәләл һәм хәрам.

**Төп әдәбият:**

1. Вәлиуллин К.Х. Ислам тәрбиясе. 1-4 сыйныфлар өчен дәреслек. — Казан: Идел-Пресс, 2016 - 256 б.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Әдһәмов Г. Гакыйдә (Иман нигезләре). Уку әсбабы. Казан: Хузур, 2014. – 160 б.
2. Максуди Ә. Гыйбадәте исламия. — Казан: Идел-Пресс, 2013. — 112 б.
3. Ислам дине нигезләре – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2016.

## 2. Әдәп-әхлак

Балаларның әти-әниләренә карата булган вазифалары.

Абый-энеләренең һәм апа-сеңелләренең бер-беренә карата булган вазифалары.

Белем алу әдәпләре.
Йокы әдәпләре.
Йөрү әдәпләре.
Җомга көн әдәпләре.

**Төп әдәбият:**

1. Вәлиуллин К.Х. Ислам тәрбиясе. 1-4 сыйныфлар өчен дәреслек. — Казан: Идел-Пресс, 2016 - 256 б.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Аль-Газали Абу Хамид. Адабы. Казань: Идел-Пресс, 2013.
2. Балаларга үгет-нәсыйхәт. Яңартылган икенче басма. — Казан: «Дом печати», 2002. — 175 б.
3. Фазлыев Җ. Иманлы бала. Тәрбия турында. — Казан: «Идел-пресс» басмаханәсе, 2003. — 144 бит.
4. Фазлыев Җ. Локман Хәким нәсыйхәтләре. Казан: Хузур, 2014.
5. Ислам дине нигезләре – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2016.

## 3. Коръән Кәрим

Татар телендәге тәфсир китаплары. «Ногмани» тәфсире (Габденнасыйр Курсави һәм Ногман бине Әмир бине Госман әс-Сәмәни). «Фәваид» тәфсире (Хөсәен Әмирхан). «Тәсһилүл бәян фи тәфсирил Куръән» тәфсире (Мөхәммәтсадыйк Иманколый). «Әл-иткан фи тәрҗимәти-л-Куръән» тәфсире (Шәйхелислам Хәмиди).

Түбәндәге сүрәләрне тәҗвид кагыйдәләре белән дөрес уку, гомум тәфсире белән танышу һәм сүрәне ятлау:
- Әл-Гадийәт сүрәсе.
- Әл-Галәк сүрәсе.

**Төп әдәбият:**

1. Һәфтияк шәриф. – Казан, 2012. – 152 бит.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Коръән Шәриф (Казан басмасы).

## 4. Фикыһ

**Нәфел намазлары.** Хаҗәт намазы. Истиска намазы. Тәүбә намазы. Хәвеф намазы. Көсуф намазы. Хөсуф намазы. Сәфәр намазы. Шөкер намазы. Ишракъ намазы. Зуха намазы. Әүвәбин намазы. Тәһәҗҗөд намазы. Һәүел намазы. Мәсҗид намазы. Истихарә намазы.

**Саум (ураза) китабы.** Ураза тотуның фарыз икәнлеге. Уразаның фарызлары. Ураза тотуга ният кылу. Сәхәр тору, ифтар кылу. Уразалы кешегә сөннәт булган эшләр. Уразалы  вакытында мәкруһ булган эшләр. Уразалы кешегә дөрес булган эшләр. Уразаны бозучы эшләр. Үз ихтыяры

белән яисә хаталык белән уразасын бозган кешенең хөкеме. Кайсы гамәлләрне эшләгән кешенең уразасы бозылмый. Кемгә ураза тоту фарыз түгел. Уразаны каза кылу. Игътикяф. Нәфел уразалар тоту.

**Төп әдәбият:**

1. Ислам дине нигезләре – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2016.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Максуди Ә. Гыйбадәте исламия. – Казан: «Матбугат йорты» нәшрияты, 2012.

## 5. Ислам тарихы

**Пәйгамбәрләр тарихы.**

**Әюп гәләйһиссәләм.** Әюб галәйһиссәләмгә ирешкән сынаулар. Аның сабырлыгы. Догасы. Бәлаләрдән котылуы.

**Муса галәйһиссәләм.** Фиргәвеннең төше. Муса галәйһиссәләмнең фиргавен сараенда үсүе. Мадьянга күченүе. Шугайб галәйһиссәләмдә хезмәт итүе. Пәйгамбәрлек вазифасына чакырылуы. Туганы Һарун галәйһиссәләмнең аңа ярдәмче итеп билгеләнүе. Могҗизалары. Мисырда фиргавенне һәм аның кавемен дингә чакыруы. Кавемен Мисырдан алып чыгуы. Тәүратның иңдерелүе. Кавеменең алтын бозау ясавы. Сыер корбан итү вакыйгасы. Хозер галәйһиссәләмнән гыйлем өйрәнүе.

**Ислам тарихыннан.** Әбү Бәкр Әс-Ситдыйкның хәлифәлеге. Гомәр әл-Хаттабның хәлифәлеге. Госман бине Гаффанның хәлифәлеге. Коръәннең бер нөсхә итеп туплануы. Гали бине Әбү Талибның хәлифәлеге.

**Татар халкының ислам тарихы.** Рус империясе чорында татарларда Ислам дине. Татар-мөселман галимнәре – Г.Курсави, Г.Утыз-Имәни, Ш.Мәрҗани.

**Төп әдәбият:**

1. Ислам дине нигезләре – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2016.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Бикбулат С. Хәзрәти Мөхәммәд. – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2014.
2. Фәхреддин Р. Мөхәммәд. – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2015.

## Алтынчы ел (16 яшьлекләр)

### 1. Гакыйдә

Аллаһы Тәгаләнең исемнәре: Әл-Бәәтыйнү, Әл-Вәәлии, Әл-Мүтәгәәлии, Әл-Бәрру, Әт-Тәүәәбү, Әл-Мүнтәкыймү (Зү Интикаам), Әл-Гәфүү, Әр-Раүфү, Мәликү-л-Мүлк, Зү-л-Җәләәли вә-л-Икраам, Әл-Мүкситу, Әл-Җәәмигү, Әл-Ганийү, Әл-Мүгнии, Әл-Мәәнигү.

Көферлек – ул Пәйгамбәребез с.г.в.с. нән катгый хәбәр ителгән нәрсәләрнең берсен генә булса да инкяр итү. Көферлек итү өч төргә бүленә икәнлеге: Беренчесе - игътикадта көферлек итү; икенчесе – сүз белән көферлек итү; өченчесе – гамәл белән көферлек итү.

Кяферләрнең төрләре: 1) Кабул итмәүче (заляләттәге) кяферләр («күфр инкәри»); 2) Кире кагучы кяферләр («күфр жүһүд»); 3) Кирелек, тәкәбберлек күрсәтүче кяферләр («күфр инәди»); 4) Ике йөзлелек күрсәтүче кяферләр (монафиклар) («күфр нифәк»).

Зур гөнаһларның аңлатмасы. Зур гөнаһларның кичерелүенә һәм Җәһәннәм утыннан котылуга китерүче гамәлләр (Аллаһы Тәгаләнең рөхсәте белән). 70 зур гөнаһны карап чыгу.

**Төп әдәбият:**

1. Ислам дине нигезләре – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2016.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Әдһәмов Г. Гакыйдә (Иман нигезләре). Уку әсбабы. Казан: Хузур, 2014. – 160 б.
2. Максуди Ә. Гыйбадәте исламия. — Казан: Идел-Пресс, 2013. — 112 б.
3. Вәлиуллин К. Ислам гакыйдәсе (Иман нигезләре). Уку әсбабы. Казан: «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе, 2016/1437. – 215 бит.

### 2. Әдәп-әхлак

Олыларга хөрмәт, сабыйларга сөйю.
Хак.
Гадәләт.
Сөйләү һәм үз-үзеңне тоту әдәпләре.
Кунакчыллык һәм кунакта булу әдәпләре.

**Төп әдәбият:**

1. Ислам дине нигезләре – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2016.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Аль-Газали Абу Хамид. Адабы. Казань: Идел-Пресс, 2013.
2. Балаларга үгет-нәсыйхәт. Яңартылган икенче басма. — Казан: «Дом печати», 2002. — 175 б.
3. Фазлыев Җ. Иманлы бала. Тәрбия турында. — Казан: «Идел-пресс» басмаханәсе, 2003. — 144 бит.
4. Фазлыев Җ. Локман Хәким нәсыйхәтләре. Казан: Хузур, 2014.

## 3. Коръән Кәрим

Түбәндәге сүрәнең тәҗвид кагыйдәләре белән дөрес уку, гомум тәфсире белән танышу һәм ятлау:

- «Әл-Бәйинәһ» сүрәсе.

**Төп әдәбият:**

1. Һәфтияк шәриф. – Казан, 2012. – 152 бит.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Коръән Кәрим китабы (тәфсире һәм укылышы белән). — Казан: «Иман» нәшр., 2009. — 1172 б.
2. Коръән Шәриф (Казан басмасы).

## 4. Фикыһ

**Зәкят китабы.** Зәкятнең телдәге һәм шәригатьтәге аңлатмасы. Кемгә зәкят бирү фарыз була. Нәрсәдән зәкят бирелми. Кемгә зәкят бирү фарыз булмый. Алтын һәм көмештән зәкят бирү. Сәүдәдән зәкят бирү. Хайваннардан зәкят бирү. Уңыштан зәкят (гошер) бирү. Зәкят бирелә торган кешеләр. Фитра садәкасы. Фидия. Садәка. Зәкят җыючыны билгеләү.

**Хаҗ китабы.** Аңлатмасы. Хаҗ кылу кемгә фарыз булуы. Әл-Ихрам. Мәккәи Мөкәррәмгә бару. Тәваф кылу. Сәгыя кылу. Мина. Гарәфәт тавы. Мөздәлифә. Минада таш ату. Тәвафи зиярат. Тәвафи садр.

**Төп әдәбият:**

1. Ислам дине нигезләре – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2016.

## 5. Ислам тарихы

**Пәйгамбәрләр тарихы.**

**Дауд галәйһиссәләм.**

Патша булып китүе. Пәйгамбәрлеге. Гадел хөкемдар булуы. Зәбур китабы иңү. Матур тавышы. Кошлар телен аңлавы. Тимер эше белән шөгыльләнүе, кольчугалар ясавы. Көн аралаш ураза тотуы.

**Сөләйман галәйһиссәләм.**

Патшалыгы. Пәйгамбәрлеге. Гадел хөкемдар булуы. Кошлар һәм хайваннар телен аңлавы. Җилнең һәм җеннәрнең аңа буйсынуы. Әл-Акса мәчетен төзәтүе. Саба кавеме башлыгы Бәлкисне дингә чакыруы. Үлеме.

**Ислам тарихыннан.**

Оммеядлар династиясе хәлифәлеге. Гомәр ибн Габделгазиз. Габбасидлар хәлифәлеге. Андалусия.

**Татар халкының ислам тарихы.**

XX гасыр башында татар халкының торышы. Җәдитчелек хәрәкәте. Олуг шәхесләр: Апанаевлар, Акчуриннар, Рәмиевләр, Хөсәеновлар, Г.Баруди, Р.Фәхретдин, М.Бигиев, З.Камали, Ә.Максуди һ.б. 1917 елгы инкыйлаб һәм татар халкының язмышы.

**Төп әдәбият:**

1. Ислам дине нигезләре – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2016.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Бикбулат С. Хәзрәти Мөхәммәд. – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2014.
2. Фәхреддин Р. Мөхәммәд. – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2015.

## Җиденче ел (17 яшьлекләр)

### 1. Гакыйдә

Аллаһы Тәгаләнең барлыгын Әбү Ханифәнең дәлилләве. Аллаһы Тәгаләнең барлыгын Җәгъфәр әс-Сәдыйкның дәлилләве. Әбү Мансур әл-Матуридиның «Китаб әт-Таухид» («Бераллалык китабы») әсәреннән Аллаһы Тәгаләнең барлыгына китерелгән дәлилләре. Аллаһы Тәгаләнең барлыгына Галәмдәге галәмәтләр. Аллаһы Тәгаләнең барлыгына кешенең төзелешеннән дәлилләр.

Аллаһы Тәгаләнең исемнәре: Әд-Даарру,Ән-Нәфиигү,Ән-Нүүру, Әл-Һәәдии, Әл-Бәдиигү, Әл-Бәәкыы, Әл-Вәәрисү, Әр-Рашиидү, Әс-Саббүүру.

Иман белән гамәлнең бәйләнеше. Кеше күңеле белән тәсдыйк итеп, теле белән шуны белдерсә, ләкин кайбер гамәлләрне эшләмәсә ул кәфер булмый, ә фәсыйк (гөнаһкәр) булуы. Аллаһы Тәгалә теләсә аны гафу итә, теләсә газап итә. Ләкин, ахыр чиктә Аллаһы Тәгалә аны Җәннәткә кертә.

Әбү Ханифә карашы буенча иман артмый да, кимеми дә, ә ул җимешләренең һәм тәкъвалыкның артуы, күңел эчкерсезлегенең көчәюе, калебтәге иман нурының яктыртуы, изге гамәлләр кылу сәбәпле, һәм көчсезләнүе, гөнаһ эшләве сәбәпле.

Иманның нык һәм хакыйкый булуның шартлары. Иманны көчәйтүче һәм көчсезләндерүче гамәлләр.

**Төп әдәбият:**

1. Ислам дине нигезләре – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2016.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Әдһәмов Г. Гакыйдә (Иман нигезләре). Уку әсбабы. Казан: Хузур, 2014. – 160 б.
2. Вәлиуллин К. Ислам гакыйдәсе (Иман нигезләре). Уку әсбабы. Казан: «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе, 2016/1437. – 215 бит.

### 2. Әдәп-әхлак

Вәгъдәдә тору.

Тәүбә.

Мәетне озату әдәпләре.

Каберләрне зиярат итү әдәпләре.
Кайгы уртаклашу әдәпләре.

**Төп әдәбият:**
1. Ислам дине нигезләре – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2016.

**Өстәмә әдәбият:**
1. Аль-Газали Абу Хамид. Адабы. Казань: Идел-Пресс, 2013.
2. Балаларга үгет-нәсыйхәт. Яңартылган икенче басма. — Казан: «Дом печати», 2002. — 175 б.
3. Фазлыев Җ. Иманлы бала. Тәрбия турында. — Казан: «Идел-пресс» басмаханәсе, 2003. — 144 бит.
4. Фазлыев Җ. Локман Хәким нәсыйхәтләре. Казан: Хузур, 2014.

### 3. Коръән Кәрим

Түбәндәге сүрәләрне тәҗвид кагыйдәләре белән дөрес уку, гомум тәфсире белән танышу һәм ятлау:
- Әл-Инширах сүрәсе.
- Әд-Духә сүрәсе.

**Төп әдәбият:**
1. Һәфтияк шәриф. – Казан, 2012. – 152 бит.

**Өстәмә әдәбият:**
1. Коръән Кәрим китабы (тәфсире һәм укылышы белән). — Казан: «Иман» нәшр., 2009. — 1172 б.
2. Коръән Шәриф (Казан басмасы).

### 4. Фикыһ

**Ризык китабы.**

Ашауның хөкемнәре. Үсемлек һәм хайван ризыклары. Ашау өчен хәрам булган хайваннар, Ашау өчен хәләл булган хайваннар. Зарурат вакыты; зарурат вакытына кагылышлы кагыйдәләр. Хәрам булган эчемлекләр. Исерткеч эчемлекләр.

**Киемнәр.**

Киемгә карата гомуми кагыйдәләр. Киемгә карата аерым кагыйдәләр. Алтын, көмеш, кыйммәтле әйберләре булган кием кию.

**Төп әдәбият:**
1. Ислам дине нигезләре – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2016.

## 5. Ислам тарихы

**Пәйгамбәрләр тарихы.**

**Юныс галәйһиссәләм.** Ниневия халкын дингә чакыруы. Кавемен ташлап китүе. Балык эченә эләгүе. Тәүбәсе, догасы һәм бәладән котылуы. Пәйгамбәрлек вазифасын дәвам итүе.

**Гайсә галәйһиссәләм.** Мәрьям радый Аллаһү ганһә. Гайсә галәйһиссәләмнең этисез дөньяга килүе. Пәйгамбәрлеге. Могҗизалары. Инҗилның иңдерелүе. Күктән ризыклар иңү вакыйгасы. Аны үтерү өчен оештырлган һөҗүм. Тере килеш күккә ашуы. Кыямәт Көне алдыннан Җиргә кайтачагы. Христианнарның Гайсә галәйһиссәләм турындагы карашлары.

**Ислам тарихыннан.** Госманлы дәүләтенең барлыкка килүе. Константинопол шәһәрен яулап алу. Госманлы дәүләтенең солтаннары. Госманлы дәүләтенең чәчәк атуы һәм таркалуы.

**Татар халкының ислам тарихы.** Совет чорында татарларда Ислам дине. Атеизм. Репрессияләр. 1989 елдан Исламның яңарышы.

**Төп әдәбият:**

1. Ислам дине нигезләре – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2016.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Бикбулат С.  Хәзрәти Мөхәммәд. – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2014.
2. Фәхреддин Р. Мөхәммәд. – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2015.

# ***МӘЧЕТ КАРШЫНДАГЫ КУРСЛАРГА ЙӨРҮЧЕ ӨЛКӘННӘР ӨЧЕН ДИНИ ТӘРБИЯ ПРОГРАММАСЫ***

**(18 ЯШЬТӘН БАШЛАП ҺӘМ ӨЛКӘНРӘК**

**БУЛГАН ОЛЫЛАР ӨЧЕН)**

# КЕРЕШ

Татарстан Республикасында эшләп килүче 1400ләп мәчетнең шактыенда әхлакый тәрбия һәм башлангыч дини белем бирүче курслар оештырыла. Анда барлык теләүчеләр – балалар да, олылар да – ислам дине нигезләрен үзләштерә. Җөмһүриятебез мәчетләрендә белем вә тәрбия алучылар саны елдан ел арта бару сәбәпле, шушы дини курсларның эшен бер тәртипкә салу, укытуның сыйфатын камилләштерү ниятеннән Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния Нәзарәте бердәм Программа булдыру максатын куйды. Әлеге максатны тормышка ашыру нияте белән махсус эш төркеме төзелде һәм фикер алышулар нәтиҗәсендә мәчетләр каршындагы курслар өчен бердәм программа эшләнде. Мәчетләргә ислам дине нигезләрен өйрәнергә килүчеләрнең төрле яшьтә булуларын исәпкә алып, программа 3 төп өлешкә бүленде: мәктәпкәчә яшьтәге 2 - 6 яшьлек балалар өчен, мәктәп яшендәге 7-17 яшьлек укучылар өчен һәм 18 яшьтән башлап олылар өчен.

Мәчетләр каршындагы курсларга йөрүче олыларга дини белем һәм тәрбия шушы программа нигезендә – ислам дине тәгълиматын тәшкил итүче төп юнәлешләр буенча бирелә. Программа ничә елга хисапланганы күрсәтелми: тәрбия алучыларның өлгерешенә карап, һәр мәхәлләдә ул кирәк кадәренчә сузылырга мөмкин (2-3 елдан алып 4-5 елга кадәр). Шунысы гына мөһим: әлеге программа олылар (18 яшьтән башлап һәм өлкәнрәк булган укучылар) өчен төзелгән.

Тәкъдим ителә торган фәннәр исемлеге һәм өйрәнелергә тиешле темалар башлангыч дини белем һәм дини тәрбия алуны, ягъни ислам дине нигезләрен өйрәнүне максат итеп куя. Шактый күп мәхәлләләрдә дини курсларның эшчәнлеге гарәп язуын, тәҗвид кагыйдәләрен һәм намаз уку тәртибен өйрәтүдән гыйбарәт. Әлеге программа шушы юнәлештә алып барылучы дәресләрне бер калыпка кертүдән тыш, өйрәнелүче фәннәр санын бераз арттыруны да күздә тота. Шулай итеп, мәчеткә дини белем вә тәрбия алырга килүчеләргә намаз уку тәртибен, гарәп язуын һәм гарәпчә Коръән

уку кагыйдәләрен генә түгел, ислам гакыйдәсе асылын, фикыһ, ягъни шәригать хөкемнәрен, ислам тарихын һәм әхлагын өйрәнергә мөмкин булачак.

Фикыһ дәресләрендә гамәлләр, пакьләнү һәм намаз бүлекләре, шулай ук ураза, зәкәт һәм хаҗ темалары өйрәнелсә, гакыйдә фәненең төп максаты – ошбу гыйбадәтләрнең кирәклеген һәм мөһимлеген аңлау, Аллаһ барлыгын - берлеген исбатлау, Аның фәрештәләре, изге Китаплары, пәйгамбәрләре, Кыямәт көне һәм тәкъдир турында гыйлем алу, тулаем алганда – ислам дине буенча яшәүнең һәм дөрес фикер йөртүнең әһәмиятенә, файдаларына төшенү.

Коръән-Кәрим дәресләренә килгәндә, шушы программа буенча шәкертләрнең тиләвәт дәресләрендә катнашып, гарәпчә Коръән уку осталыкларын яхшырту өстендә эшләү каралган. Моннан тыш Коръән-Кәрим программасы хифз (Коръән сүрәләрен ятлау) һәм тәфсир (Коръән аятьләренең мәгънәләре белән танышу) дәресләрен дә үз эченә ала. Тәфсир фәне Коръәнне шәрехләү ысуллары, шулай ук «Фатиха» һәм ахыргы кыска сүрәләрнең эчтәлек - мәгънәләре белән таныштыра. Хифз дәресләрендә Коръәннән кайбер сүрәләрне генә түгел, гамәл - гыйбадәт кылу өчен кирәкле догаларны өйрәнү дә күздә тотыла. Әлеге дәрес беренче уку елында “Коръән сүрәләрен, намаз зикерләрен һәм көндәлек догаларны ятлау” дип билгеләнә, чөнки мәчеткә башлангыч дини белем алырга килүче кеше өчен намаз уку тәртибен дөрес итеп өйрәнү бик мөһим максат булып тора. Шул уңайдан беренче уку елында ятлату һәм ятланганны сорау, хаталар өстендә эшләү мәсьәләсенә күбрәк игътибар итәргә киңәш ителә . Икенче, өченче уку елларында Хифз дәресе “Коръән сүрәләрен һәм догалар ятлау” дип кенә тәгаенләнә. Һәр яңа дәрес узган дәрестә өйрәнелеп ятларга бирелгән сүрәне (зикер-доганы) яттан сораудан башлансын. Мөгаллимнең бурычы – һәр шәкерттән ятланганны сорап, укылышны бәяләү (билге кую), хаталы урыннар булса – төзәтү.

Ислам тарихы программасы Мөхәммәд пәйгамбәрнең (с.г.в.с.) тәржемәи хәлен, тормыш юлын өйрәнүне максат итеп куя. Тугры хәлифәләр белән бәйле булган мәгълүматны һәм татар халкында ислам дине үсешенә багышланган темаларны үзләштерү дә шушы юнәлешнең максаты булып тора.

Мәчет каршындагы курсларда әхлак фәненә бик зур әһәмият бирелә һәм барлык уку еллары дәвамында да үз-үзеңне тоту, башкалар белән мөгамәлә кору, Аллаһка, пәйгамбәргә, остазга, әти - әнигә вә башка кешеләргә карата әдәп кагыйдәләре һәрдаим истә тотылырга һәм игътибар үзәгендә булырга тиеш. Шул максатта, гомуми уку вакытын файдаланудан тыш, мөмкинлектән чыгып, өстәмә вәгазьләр һәм очрашулар оештырырга мөмкин.

Мәчет каршындагы курсларда дәресләр, гадәттә, октябрь башыннан апрель ае азагына кадәр бара: беренче яртыеллыкта 12-13 атна (октябрь, ноябрь, декабрь), икенче яртыеллыкта 15-16 атна (гыйнвар, февраль, март, апрель). Уку көннәрен һәм вакытын төркем туплангач, үзара сөйләшеп билгеләргә мөмкин (иртә, көндез, кич яки шимбә-якшәмбе).

Белем алу уңышлы, нәтиҗәле булсын өчен укучыларга кайбер таләпләр куелсын. Әйтик, үткән теманы искә төшерү өчен бергәләп кабатлау, уку, хаталарны төзәтү; шулай ук өйрәнелгәнне ныгыту өчен үз вакыты белән язма эшләр, тестлар үткәрү файдалы була, уку елы ахырында исә нәтиҗә чыгаруны күздә тота торган дәрес үткәрелергә мөмкин. Мондый тәртип шәкертләрдә тырышлык вә җаваплылык хисе тәрбияләүгә һәм мөмкин кадәр яхшы нәтиҗәләргә ирешүгә бер сәбәп-этәргеч булыр иде, иншә Аллаһ. Әлбәттә, һәр төркемдә шәкертләргә индивидуаль якын килү, мәсәлән, кайбер олы яшьтәгеләрнең ятлау сәләте йомшаграк булуын аңлап эш итү, белем-тәрбия алучыларга каты басым ясамау кебек психологик үзенчәлекләр исәпкә алынырга тиеш.

Аңлашыла ки, һәр авыл мәчетендә дә шушы программада каралган барлык фәннәрне укыта алырлык мөгаллимнәр булмаска да мөмкин. Бу

очракта мөхтәсибәт белән килешеп, мөгаллимне билгеле бер көнгә килү шарты белән читтән чакырырга, йә булмаса мәхәлләдә яшәүче остаз укыта алырлык фәннәр буенча гына белем бирергә мөмкин. Һәрхәлдә, аерым фәннәр генә укытылган очракта да, мөгаллимнең шушы программага таянып эш итүе мәслихәт, ягъни биредә тәкъдим ителә торган тематик планнар, әдәбият исемлекләре һ.б. мәчет каршында башлангыч дини белем вә тәрбия бирүче мөгаллимнәр өчен гомум кабул ителгән үрнәк буларак хезмәт итсен иде.

Шунысы да мөһим: һәр программа уку-укыту процессында сыналырга, фән теле белән әйткәндә, “апробация” үтәргә тиеш. Шуңа күрә алга таба ул мөгаллимнәрнең, дин белеме бирүче остазларның киңәш-тәкъдимнәрен исәпкә алып, әле тагын да камилләшергә мөмкин. Моның өчен, дини мәгърифәтебез торышы, үсеше өчен битараф булмыйча, эшлекле тәкъдимнәребезне җиткерергә, киңәшергә кирәк.

Башлангыч дини гыйлем – ул ислам мәгарифенең чишмә башы. Шушы чишмә “суын” авыз итәргә теләүчеләргә дин белеме биреп, хәерле, файдалы эшләр башкарырга язсын, изге эшебездә Аллаһы Тәгалә Үзе ярдәмче булып, әҗер-савапларын ахирәттә күрергә насыйп кылсын.

## ТӘРБИЯ ПЛАНЫ

**Дини тәрбия юнәлешләре:**

**1. Гарәп язуы һәм тәҗвид:**
1.1. *Гарәп әлифбасын өйрәнү;*
1.2. *Тәҗвид кагыйдәләрен өйрәнү.*

**2. Коръән-Кәрим:**
2.1. *Хифз (Коръән сүрәләрен, намаз зикерләрен һәм көндәлек догаларны ятлау);*
2.2. *Тиләвәт (гарәпчә Коръән уку);*
2.3. *Тәфсир (Коръән аятьләренең мәгънәләре).*

**3. Фикыһ (гыйбадәт нигезләре).**

**4. Гакыйдә (исламда дөньяга караш).**

**5. Ислам тарихы**
5.1. *Мөхәммәд пәйгамбәрнең (с.г.в.с.) тормыш юлы;*
5.2. *Тугры хәлифәләр турында мәгълүмат;*
5.3. *Татарларда ислам дине тарихы.*

**6. Әдәп-әхлак (мөселман әдәбе вә әхлагы).**

# 1. Гарәп язуы һәм тәҗвид

## 1. 1. Гарәп әлифбасын өйрәнү буенча тематик план

| № | Тема |
|---|---|
| 1. | Кереш. Гарәп әлифбасының өйрәнүнең максаты, гарәп язуының үзенчәлекләре. Таблица төзү. Хәрефләр һәм авазлар системасын аңлату. Кыска сузыклар. |
| 2. | ا , ر һәм ز хәрефләрен өйрәнү һәм шушы хәрефләр белән бәйле күнегүләрне уку (“Мүгаллим сәни” китабы буенча). |
| 3. | م һәм ت хәрефләрен өйрәнү һәм шушы хәрефләр белән бәйле күнегүләрне уку. |
| 4. | ن , ي һәм ب хәрефләрен өйрәнү һәм шушы хәрефләр белән бәйле күнегүләрне уку. |
| 5. | ك һәм ل хәрефләрен өйрәнү һәм шушы хәрефләр белән бәйле күнегүләрне уку. |
| 6. | و һәм ه хәрефләрен өйрәнү һәм шушы хәрефләр белән бәйле күнегүләрне уку. |
| 7. | ف һәм ق хәрефләрен өйрәнү һәм шушы хәрефләр белән бәйле күнегүләрне уку. |
| 8. | ش , س һәм ث хәрефләрен өйрәнү һәм шушы хәрефләр белән бәйле күнегүләрне уку. |
| 9. | ص һәм ط хәрефләрен өйрәнү һәм шушы хәрефләр белән бәйле күнегүләрне уку. |
| 10. | ج , خ һәм ح хәрефләрен өйрәнү һәм шушы хәрефләр белән бәйле күнегүләрне уку. |
| 11. | غ һәм ع хәрефләрен өйрәнү һәм шушы хәрефләр белән бәйле күнегүләрне уку. |
| 12. | د һәм ض хәрефләрен өйрәнү һәм шушы хәрефләр белән бәйле күнегүләрне уку. |
| 13. | ذ һәм ظ хәрефләрен өйрәнү һәм шушы хәрефләр белән бәйле күнегүләрне уку. |
| 14. | Мәдле хәрефләр. |

| | |
|---|---|
| 15. | Калькалә хәрефләре. |
| 16. | Тәшдидле хәрефләр. |
| 17. | Тәнвинле хәрефләр. Гарәп телендә килешләр. |
| 18. | Тәнвинле тәшдид. |
| 19. | Әлиф һәм һәмзә. |
| 20. | Тә мәрбута. Гарәп телендәге исемнәрнең җенесе. |
| 21. | Әлиф мукаддәра. Язылмаса да укыла торган хәрефләр:<br>- « ا » (Әлиф) мукаддәра.<br>- « ى » (Йәй) мукаддәра.<br>- « و » (Уау) мукаддәра. |
| 22. | Әлиф кебек укыла торган хәрефләр:<br>- йә әлифияһ.<br>- вау әлифияһ. |
| 23. | «Әл» артикле, Ай һәм Кояш хәрефләре.<br>Васыл кагыйдәләре:<br>- Изһар камәрия.<br>- Идгам шәмсия. |
| 24. | Нәтиҗә чыгару дәресе. |

**Төп әдәбият:**


1. Әхмәдһади Максуди. Мөгаллим сәни. – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2015.

2. Курамшин Р.И. Башлангыч мәдрәсәләр һәм мәчетләр каршындагы курслар өчен тәҗвид дәреслеге. – Казан: “Хузур” нәшрияты, 2016.

## 1.2. Тәҗвид кагыйдәләрен өйрәнү буенча тематик план

| № | Тема |
|---|---|
| 1. | Беренче уку елында өйрәнелгәнне кабатлау: хәрефләрнең дөрес укылышы, язылышы. *Хәрефләрне укырга ярдәм итүче билгеләр: хәрәкәләр, сәкен, тәнвин, тәшдид* («Мүгаллим сәни»дән уку).<br><br>«Тә-мәрбүта» ( ة ) хәрефе, укылыш үзенчәлекләре (хәрәкәле тә-мәрбүтаның дәвам иткәндә һәм тукталганда укылышы).<br><br>Уку: «Мүгаллим сәни» дән 28 бит. |
| 2. | *Истигалә һәм истифәлә хәрефләре*. «Мүгаллим сәни» дән калын әйтелешле хәрефләрнең күнегүләрен уку, нечкә әйтелешле хәрефләр белән чагыштыру.<br><br>*Калкалә хәрефләре*. Күнегүләр уку, калкалә мисалларын табу (мәсәлән, «Мүгаллим сәни» дә 14 нче ( ح ) хәрефе күнегүендә) һәм 15 нче биттә ( ع ). Кагыйдәне «Ихлас», «Фәләкъ» сүрәләре мисалында аңлату. |
| 3. | *Сузык авазлар.*<br><br>«Мүгаллим сәни» дән 18-22 бит уку, һәр укучыга сузык авазны (табигый мәдне) дөрес, төгәл укуга ирешүне максат итеп кую (бигрәк тә 2 мәдле, ягъни 2 сузуы булган сүзләрдә). |
| 4. | *Язылмаса да укыла торган хәрефләр*: ا , و һәм ى мүкаддәра.<br><br>Уку: «Мүгәллим сәни», 28 бит. |
| 5. | Язылса да, укылмый торган хәрефләр: һәм Әлифия.<br><br>Уку: «Мүгаллим сәни», 29 бит. |
| 6. | *«Әл» артикле* ( أل ). *Кояш һәм ай хәрефләре.*<br><br>Уку: «Мүгаллим сәни», 30 бит. |
| 7. | *«Васыл» кагыйдәсе.*<br><br>Уку: «Мүгаллим сәни», 31 бит. |
| 8. | *«Әлиф» һәм «Ләм» кагыйдәсе*. Кабатлау. |
| 9. | *«Ра» кагыйдәсе*. Кабатлау, уку. |
| 10. | *Хәмзә билгесе*. Хәмзәнең язылу төрләре (мисаллар белән). |

| | |
|---|---|
| | Уку: «Мүгаллим сәни», 26 – 27 бит.<br><br>Өйрәнелгән темаларны кабатлау, уку, кагыйдәләрне барлап аңлату. |
| 11. | *Сәкенле «нун» һәм тәнвиннең 5 кагыйдәсе*: 1. «Изһар»; 2. «Идгам мәгәл гуннә»; 3. «Идгам биләә гуннә»; 4. «Иклаб»; 5. «Ихфә мәгәл гуннә».<br><br>Уку: Кыска сүрәләрдә һәрбер кагыйдәне табу, дөрес уку (мәсәлән, “Мәсәд”, “Һүмәзәһ” сүрәләре). |
| 12. | *Мәдләр* (гомуми аңлатма). Мәднең төрләре:<br>1. «Мәд табигый»;<br>2. «Мәд моттасыйл»;<br>3. «Мәд монфәсыйл»;<br>4. «Мәд гарыйз»;<br>5. «Мәд ләзим»;<br>6. «Мәд лин».<br><br>Уку: Коръәннән мисаллар табу, мәдләрне дөрес укып күрсәтү (мәсәслән, “Бәкара” сүрәсеннән “Әлиф-Ләәм-Миим”; “Әли Гыймран” сүрәсеннән “Әлләзиинә” һәм “Шәһидәллааһ” аятьләре; “Әддухә”, “Курайш” сүрәләре). |
| 13. | *Сәкенле «Мим» кагыйдәләре*:<br>1. «Идгам мисләин мәгәл гуннә»;<br>2. «Ихфә шәфәвия»;<br>3. «Изһар».<br><br>Уку: Коръәннән мисаллар табу, укып күрсәтү (мәсәлән, “Гәдият” сүрәсе, “Маидә” сүрәсе 90-93 аятьләр). |
| 14. | *«Идгам мисләин» кагыйдәсе*:<br>1. «Идгам мисләин мәгәл гуннә»;<br>2. «Идгам мисләин биләә гуннә».<br><br>Уку: мисаллар табу, укып күрсәтү (мәсәлән “Мөлк” сүрәсе 19-21 аятьләр; “Ниса” сүрәсе 78 аять, “Йәсин” сүрәсе 18-24 аятьләр). |
| 15. | *«Идгам мүтәҗәнисәин» кагыйдәсе.* Мисаллар уку (мәсәлән, “Кәфирун” сүрәсе; “Һуд” сүрәсе, 42 аять; “Әгъраф” сүрәсе, 176 аять). |
| 16. | *«Идгам мүтәкарибәин» кагыйдәсе.* Мисаллар уку (мәсәлән, “Ниса” сүрәсе 158 аять; “Мүрсәләт” сүрәсе 20 аять). |
| 17. | *«Тәксир тәнвин» кагыйдәсе.* Мисаллар уку (мәсәлән, “Кәһеф” сүрәсе 77, 88 аятьләр яки “Тәксир тәнвин” кагыйдәләре язылган аерым бит). |

| | |
|---|---|
| 18. | *«Вакыф» кагыйдәсе*: гомуми аңлатма; вакыф кылуны рөхсәт итүче билгеләр; вакыф кылу үзенчәлекләре. Коръәндәге мисаллар буенча аңлатма бирү (мәсәлән, “Бәкара” сүрәсеннән “Аятел-Көрси”). |
| 19. | *«Сәктә» кагыйдәсе.*<br><br>Коръәндәге 4 мисалны уку: “Кәһеф” сүрәсе, 1нче аять ахыры; “Йәсин”сүрәсе, 52нче аять; “Кыямәт” сүрәсе, 27нче аять; “Мутаффифин” сүрәсе, 14нче аять. |
| 20. | *« ه » алмашлыгы.* «һә» гә тәмамланучы сүзләргә тукталу (вакыф кылу) үзенчәлекләре. |
| 21. | Өстәмә: *Раум ишмам. Коръәннең өлешләргә бүленүе.* |
| 22. | Кабатлау: Коръән аятьләрен укып, тәҗвид кагыйдәләрен барлау. |
| 23. | Нәтиҗә чыгару дәресе. |

**Төп әдәбият:**


1. Коръән (Казан басмасы).
2. Курамшин Р.И. Башлангыч мәдрәсәләр һәм мәчетләр каршындагы курслар өчен тәҗвид дәреслеге. – Казан: “Хузур” нәшрияты, 2016.

## 2. Коръән-Кәрим

### 2.1. Хифз (Коръән сүрәләрен, намаз зикерләрен һәм көндәлек догаларны ятлау) буенча тематик план

Искәрмәләр:

1) Беренче елда әлеге юнәлеш программасы белем-тәрбия алучыларның кыска сүрәләрдән тыш намаз уку тәртибен өйрәнүне дә максат итеп куя.

2) Һәр дәрес узган атнада өйрәнелеп ятларга бирелгән сүрәне (зикер-доганы) яттан сораудан башлана. Дәреснең икенче өлеше яңа сүрәнең (дога-зикернең) дөрес укылышын үзләштерүгә багышлана.

**I өлеш**

| № | Тема |
|---|---|
| 1. | «Әгузү - Бисмилләһ», «Кәлиматүн - таййибәтүн», «Кәлиматүшшәһәдәт» дөрес укылышы, тәрҗемәсе (мәгънәләренә бәйләп, кыскача вәгазь). |
| 2. | «Сәнә» догасы – дөрес укылышы, тәрҗемәсе белән таныштыру. |
| 3. | «Фатиха» сүрәсе – дөрес укылышы, мәгънәсе белән таныштыру. |
| 4. | «Кәүсәр» сүрәсе – дөрес укылышы, мәгънәсе белән таныштыру. |
| 5. | «Ихлас» сүрәсе – дөрес укылышы, мәгънәсе белән таныштыру. |
| 6. | «Әттәхият» зикере – дөрес укылышы, тәрҗемәсе белән таныштыру. |
| 7. | «Салават» зикере – дөрес укылышы, тәрҗемәсе белән таныштыру. |
| 8. | «Раббәнәә» һәм «Сәләм» догалары – дөрес укылышы, тәрҗемәсе белән таныштыру. |
| 9. | Ике рикәгатьле намаз уку тәртибе (намаздагы кыска зикерләрнең дөрес әйтелеше һәм намаз хәрәкәтләре белән таныштыру, практик аңлатма). |
| 10. | Азан һәм камәт (әйтелеше, мәгънәсе). |
| 11. | Азан догасы – дөрес укылышы, тәрҗемәсе белән таныштыру. |
| 12. | Ике рикәгатьле намазның укылышын тикшереп карау. |
| 13. | Мәчеткә кергәндә һәм чыкканда укыла торган догалар.<br>Ике рикәгатьле намазның укылышын тикшереп карау. |
| 14. | «Фәләкъ» сүрәсе – дөрес укылышы, мәгънәсе белән таныштыру. |
| 15. | «Нәс» сүрәсе – дөрес укылышы, мәгънәсе белән таныштыру. |

| | |
|---|---|
| 16. | Ашаганнан соң укыла торган дога – дөрес укылышы, тәрҗемәсе белән таныштыру.<br>4 рикәгатьле намаз уку тәртибе (практик аңлатма). |
| 17. | «Кунут» догасы – дөрес укылышы, тәрҗемәсе белән таныштыру. |
| 18. | Витр-вәҗеб намазы укылышы тәртибен аңлату.<br><br>«Әс-Саффәт» сүрәсенең 180 - 182 нче аятьләре («Сүб(е)хәәнә Раббикә Раббиль гыйззәти...») – дөрес укылышы, мәгънәсе белән таныштыру. Бәдрәфкә кергәндә һәм чыкканда укыла торган догалар – дөрес укылышы, тәрҗемәсе белән таныштыру. |
| 19. | «Мәсәд» сүрәсе – дөрес укылышы, мәгънәсе белән таныштыру. |
| 20. | «Нәср» сүрәсе – дөрес укылышы, мәгънәсе белән таныштыру. |
| 21. | Утыргач укыла торган дога һәм өйдән чыкканда укыла торган дога – дөрес укылышы, тәрҗемәсе белән таныштыру. |
| 22. | Үткән дәрестә өйрәнелгән доганы яттан сорау.<br><br>«Кәфирун» сүрәсе – дөрес укылышы, мәгънәсе белән таныштыру. |
| 23. | Зикер - тәсбих: «Тәмҗид кәлимәсе» («Сүб(е)хәнәллаһи үәлхәмдү лилләһи...») – дөрес укылышы, тәрҗемәсе белән таныштыру. |
| 24. | Зикер - тәсбих: «Аятүлкүрси» – дөрес укылышы, мәгънәсе белән таныштыру. |
| 25. | Зикер - тәсбих: «Тәүхид кәлимәсе» – дөрес укылышы, тәрҗемәсе белән таныштыру. |
| 26. | «Мәгун» сүрәсе – дөрес укылышы, мәгънәсе белән таныштыру. |
| 27. | «Курайш» сүрәсе – дөрес укылышы, мәгънәсе белән таныштыру. |
| 28. | «Фил» сүрәсе – дөрес укылышы, мәгънәсе белән таныштыру. |
| 29. | Кабатлау, тапшырылып бетмәгән сүрәләрне һәм дога-зикерләрне сорау. |

## II өлеш

| | |
|---|---|
| 1. | «Иман мүфәссаль» - иман китерү кәлимәсе (“Әмәнтү билләһи...”) – дөрес укылышы, тәрҗемәсе белән таныштыру. |
| 2. | «Үәл-Гаср» сүрәсе – дөрес укылышы, мәгънәсе белән таныштыру. |
| 3. | «Тәүбә - истигъфәр» кәлимәсе – дөрес укылышы, тәрҗемәсе белән таныштыру. |
| 4. | «Һүмәзәһ» сүрәсе – дөрес укылышы, мәгънәсе белән таныштыру. |
| 5. | Ураза ае догалары («Сәхәр» һәм «Ифтар» догасы) – дөрес укылышы, тәрҗемәсе белән таныштыру. |
| 6. | «Тәкәәсүр» сүрәсе – дөрес укылышы, мәгънәсе белән таныштыру. |
| 7. | «Кааригаһ» сүрәсе – дөрес укылышы, мәгънәсе белән таныштыру. |
| 8. | Йокыдан торгач укыла торган дога – дөрес укылышы, тәрҗемәсе белән таныштыру. |
| 9. | «Гадийәәт» сүрәсе – дөрес укылышы, мәгънәсе белән таныштыру. |
| 10. | Эшне башлар алдыннан укыла торган дога – дөрес укылышы, тәрҗемәсе белән таныштыру. |
| 11. | «Зәлзәлә» сүрәсе – дөрес укылышы, мәгънәсе белән таныштыру. |
| 12. | Үлем хәбәре ишеткәч укыла торган дога – дөрес укылышы, тәрҗемәсе белән таныштыру. |
| 13. | «Кадер» сүрәсе – дөрес укылышы, мәгънәсе белән таныштыру. |
| 14. | Корбан гаетендә, тәшрик көннәрендә укыла торган зикер (Аллаһү әкбәр, Аллаһү әкбәр...) |
| 15. | «Тин» сүрәсе – дөрес укылышы, мәгънәсе белән таныштыру. |
| 16. | Зиратка кергәндә укыла торган дога – дөрес укылышы, тәрҗемәсе белән таныштыру. |
| 17. | «Инширах» сүрәсе – дөрес укылышы, мәгънәсе белән таныштыру. |
| 18. | «Духәә» – дөрес укылышы, мәгънәсе белән таныштыру. |
| 19. | Кабатлау, хаталар өстендә эшләү. |

**III өлеш**

| | |
|---|---|
| 1. | 7 кәлимә турында мәгълүмат. «Кәлимәтүн таййибәтүн», «Кәлимәтүшшәһәәдәти»: кабатлау, дөрес әйтелешне, мәгънә - тәрҗемәне искә төшерү.<br><br>«Кәлимәтү-тәүхид» (тулы вариант). |
| 2. | «Бәкара» сүрәсеннән «Әлиф-Ләм-Мим» (1 - 5 нче аятьләр) – дөрес укылышы, мәгънәсе белән таныштыру. |
| 3. | «Раддиль-күфри» кәлимәсе – дөрес укылышы, тәрҗемәсе белән таныштыру. |
| 4. | «Бәййинәһ» сүрәсе – дөрес укылышы, мәгънәсе белән таныштыру. (Сүрәне өч кисәккә бүлеп ятлаттырырга мөмкин: 1 - 4 нче аятьләр; 5 - 6 нчы аятьләр; 7 - 8 нче аятьләр). |
| 5. | «Кәлимәтүл-истигъфәр» – дөрес укылышы, тәрҗемәсе белән таныштыру. |
| 6. | «Галәкъ» сүрәсе – дөрес укылышы, мәгънәсе белән таныштыру. (Сүрәне өч кисәккә бүлеп ятлаттырырга мөмкин: 1- 7 нче аятьләр; 8 -14 нче аятьләр; 15 -19 нчы аятьләр). |
| 7. | «Тиләвәт сәҗдәсе» догасы – дөрес укылышы, тәрҗемәсе белән таныштыру. |
| 8. | «Бәкара» сүрәсеннән «Фәзкүруни» (152 - 157 нче аятьләр) – дөрес укылышы, мәгънәсе белән таныштыру. (Әлеге өзекне ике кисәккә бүлеп ятлаттырырга мөмкин: 152 - 154 нче аятьләр; 155 - 157 нче аятьләр). |
| 9. | «Кәлимәтү-тәмҗид» (тулы вариант: «Әл-Иимәәнү икърарум бильлисәәни...» дигән өстәмә белән) – дөрес укылышы, тәрҗемәсе белән таныштыру. |
| 10. | «Бәкара» сүрәсеннән «Шәһрурамәдан» (185 - 186 нчы аятьләр) – дөрес укылышы, мәгънәсе белән таныштыру. |
| 11. | «Иман-мүҗмәл» кәлимәсе – дөрес укылышы, тәрҗемәсе белән таныштыру. |
| 12. | «Бәкара» сүрәсеннән «Лилләһи» (284 - 286 нчы аятьләр) – дөрес укылышы, мәгънәсе белән таныштыру. (Әлеге өзекне ике кисәккә бүлеп ятлаттырырга мөмкин: 284 - 285 нче аятьләр; 286 нче аять). |
| 13. | «Иман-мүфәссаль» кәлимәсе – дөрес укылышын һәм тәрҗемәсен искә төшерү. |

| | |
|---|---|
| 14. | «Хәшер» сүрәсеннән «Ләә йәстәви» (20 - 24 нче аятьләр) – дөрес укылышы, мәгънәсе белән таныштыру. (Әлеге өзекне ике кисәккә бүлеп ятлаттырырга мөмкин: 20 - 22 нче аятьләр; 23-24 нче аятьләр). |
| 15. | «Тәсбих» догасы – дөрес укылышы, тәрҗемәсе белән таныштыру. (Әлеге доганы ике кисәккә бүлеп ятлаттырырга мөмкин: беренче яртысы (“йәә мәүләәнәә” гә кадәр); икенче яртысы (ахырына кадәр). |
| 16. | «Саффәт» сүрәсеннән өзекләр: 79-81, 109-111, 120-122, 130-131 нче аятьләр (“Сәләәмүн гәләә...”). |
| 17. | Коръән багышлау, татарча дога кылу тәртибе. |
| 18. | Тапшырылып бетмәгән дога-сүрәләрне сорау. Кабатлау, хаталар өстендә эшләү. |

**Төп әдәбият:**

1. Ислам дине нигезләре – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2016.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Коръән Шәриф (Казан басмасы).

2. Коръән-Кәрим китабы (тәфсире һәм укылышы белән). – Казан: «Иман» нәшрияты, 2009.

## 2.2. Тиләвәт (гарәпчә Коръән уку) буенча тематик план

| № | Тема |
|---|---|
| 1. | «Коръән» турында әңгәмә. Коръән уку әдәбе. «Коръән» укуның фазыйләтләре. |
| 2. | 1-2 сыйныфта ятлаган сүрәләрне кабатлау: гарәпчә язылышын текст буенча күзәтеп, кагыйдәләрне барлап, мөгаллим белән укып чыгу. |
| 3. | Тәҗвид кагыйдәләрен кабатлау.<br><br>«Бәййинәһ»тән «Әд-Духәгә» кадәр сүрәләр уку. |
| 4. | «Нәбә», «Мүлек», «Йәсин», «Рахмән» сүрәләрен уку. |
| 5. | «Йәсин» сүрәсендә барлык тәҗвид кагыйдәләрен барлап, кабатлау. |

Искәрмә: *2 атнага бер тапкыр тәҗвид кагыйдәләрен барларга кушып, ике-өч юлдан торган язмача өй эше бирү киңәш ителә.*

**Төп әдәбият:**

1. Коръән-Кәрим (Казан басмасы).

**Өстәмә әдәбият:**

1. Коръән Кәрим китабы (тәфсире һәм укылышы белән). – Казан: «Иман» нәшрияты, 2009.

## 2.3. Тәфсир (Коръән аятьләренең мәгънәләре) буенча тематик план

| № | Тема |
|---|---|
| 1. | Кереш. Тәфсир гыйлеме турында гомуми аңлатма. Кулланышта булган рус һәм татар телендәге тәфсирләр. Тәфсир ясау ысуллары. |
| 2. | “Фәтихә” сүрәсенең тәфсире. |
| 3. | “Нәс” сүрәсенең тәфсире. |
| 4. | “Фәләк” сүрәсенең тәфсире. |
| 5. | “Ихлас” сүрәсенең тәфсире. |
| 6. | “Мәсәд” сүрәсенең тәфсире. |
| 7. | “Нәср” сүрәсенең тәфсире. |
| 8. | “Кәфирун” сүрәсенең тәфсире. |
| 9. | “Кәүсәр” сүрәсенең тәфсире. |
| 10. | “Мәгун” сүрәсенең тәфсире. |
| 11. | “Курайш” сүрәсенең тәфсире. |
| 12. | “Фил” сүрәсенең тәфсире. |
| 13. | “Һүмәзәһ” сүрәсенең тәфсире. |
| 14. | “Үәл-гаср” сүрәсенең тәфсире. |
| 15. | “Тәкәсүр” сүрәсенең тәфсире. |
| 16. | “Каригаһ” сүрәсенең тәфсире. |
| 17. | “Гәдият” сүрәсенең тәфсире. |
| 18. | “Зәлзәлә” сүрәсенең тәфсире. |
| 19. | “Кадер” сүрәсенең тәфсире. |
| 20. | “Аятүл Күрси”нең тәфсире. |
| 21. | Нәтиҗә чыгару, вәгазь. |

**Төп әдәбият:**

1. Ислам дине нигезләре – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2016.

**Өстәмә әдәбият:**

1. «Әл-иткан фи тәрҗүмәтил-Курьән». Корьән тәрҗемәсендәге камиллек. – Казан: «Матбугат йорты» нәшрияты, 2005.

3. Коръән-Кәрим китабы (тәфсире һәм укылышы белән). – Казан: «Иман» нәшрияты, 2009.

## 3. Фикыһ (гыйбадәт нигезләре) буенча тематик план

### I өлеш

| № | Тема |
|---|---|
| | **Гыйбадәт** |
| 1. | Гыйбадәт нәрсә ул? |
| 2. | Гыйбадәт төрләре |
| 3. | Гыйбадәт дәрәҗәләре |
| 4. | Гыйбадәтнең файдасы |
| 5. | Исламда мәзһәбләр |
| 6. | Галимнәр − пәйгамбәрләрнең варислары |
| 7. | Белмәгәннәр белгәннәрдән сорасын |
| 8. | Сораулар һәм биремнәр |
| | **Ислам** |
| 9. | Нәрсә ул Ислам? |
| 10. | Исламның шартлары |
| 11. | Кем ул мөкәлләф? |
| 12. | Мөкәлләфнең вазыйфалары |
| 13. | Сораулар һәм биремнәр |
| | **Чистарыну** |
| 14. | Ислам чисталыкка нинди әһәмият бирә? |
| 15. | Суның төрләре |
| 16. | Истинҗә |
| 17. | Истибрә |
| 18. | Бәдрәфкә керү кагыйдәләре |
| 19. | Тәһарәт алуның файдасы |

| | |
|---|---|
| 20. | Тәһарәтнең фарызлары |
| 21. | Тәһарәтнең сөннәтләре |
| 22. | Тәһарәт алу тәртибе |
| 23. | Тәһарәтнең мәкруһлары |
| 24. | Тәһарәтне боза торган хәлләр |
| 25. | Тәһарәтсезниләр эшләргә ярамый? |
| 26. | Күн читекләрне мәсех кылу |
| 27. | Бәйләвеч өстеннән сөртү |
| 28. | Госел |
| 29. | Гозер хәле |
| 30. | Нәҗасәт |
| 31. | Хатын-кызның физиологик үзенчәлекләре |
| 32. | Тәяммүм |
| 33. | Гаурәтне каплау |
| 34. | Хиҗабның әһәмияте турында |
| 35. | Гаурәтне ничек итеп капларга кирәк |
| 36. | Тирә-як мохитнең чисталыгы |
| 37. | Сораулар һәм биремнәр |
| | **Намаз уку тәртибе** |
| 38. | Намазның мөһимлеге. Кемнәр намаз укырга бурычлы? |
| 39. | Намаз вакытлары |
| 40. | Намаз төрләре |
| 41. | Намазның фарызлары |
| 42. | Намазның ваҗибләре |
| 43. | Намазның сөннәтләре |

| | |
|---|---|
| 44. | Намазның әдәпләре |
| 45. | Намазны боза торган хәлләр |
| 46. | Намаз вакытында хуш күрелмәгән эшләр (мәкруһ) |
| 47. | Намаз уку тәртибе |
| 48. | Иртәнге намаз |
| 49. | Өйлә намазы |
| 50. | Икенде намазы |
| 51. | Ахшам намазы |
| 52. | Ястү намазы |
| 53. | Витр намазы |
| 54. | Намаздан соңниләр укыла |
| 55. | Дога – Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт |
| 56. | Намаздан соң укыла торган догалар |
| 57. | Сәһү сәҗдәсе |
| 58. | Тиләвәт сәҗдәсе |
| 59. | Шөкер сәҗдәсе |
| 60. | Намаз өчен әҗер-савап алу шартлары |
| 61. | Зикер – Аллаһны мактау |
| 62. | Салават укуның файдасы |

**II өлеш**

| | **Намазга кагылышлы башка сораулар** |
|---|---|
| 1. | Мәчетләр турында |
| 2. | Мәчетләрнең архитектур үзенчәлекләре |
| 3. | Мәчеттә үзеңне тоту әдәбе |

| | |
|---|---|
| 4. | Җәмәгать белән кылынган намазның өстенлеге |
| 5. | Җәмәгать белән намаз ничек укыла |
| 6. | Җомга көне һәм җомга намазы |
| 7. | Җомга намазын кылу |
| 8. | Бәйрәм намазлары |
| 9. | Бәйрәм намазлары ничек укыла |
| 10. | Тәшрик тәкбире |
| 11. | Тәравих намазы |
| 12. | Намазны утырып һәм күзләр белән уку |
| 13. | Юлчының намазы |
| 14. | Калдырылган намазларның казасы |
| 15. | Җеназа намазы |
| 16. | Җеназа намазы кылу тәртибе |
| 17. | Сораулар һәм биремнәр |
| | **Ураза** |
| 18. | Уразаның әһәмияте |
| 19. | Уразаның файдасы |
| 20. | Ураза төрләре |
| 21. | Рамазан аенда ураза тоту кемнәргә фарыз |

| | |
|---|---|
| 22. | Уразаны Рамазан аеннан кичектереп бүтән вакытта тотарга рөхсәт биргән сәбәпләр |
| 23. | Уразаның нияте |
| 24. | Сәхәр һәм ифтар |
| 25. | Уразаны бозмый торган хәлләр |
| 26. | Ураза вакытында эшләнүе мәкруһ булган гамәлләр |
| 27. | Ураза вакытында эшләнүе мәкруһ булмаган гамәлләр |
| 28. | Уразаны боза торган, әмма каза уразасын гына таләп итә торган хәлләр |
| 29. | Уразаны боза торган һәм каза уразасы белән кәффарәтне үтәүне таләп итә торган хәлләр |
| 30. | Игътикаф |
| 31. | Фидия |
| 32. | Фитр сәдакасы |
| 33. | Рамазан аенда җитди сәбәпсез уразасын калдырган кешенең хәле |

**III өлеш**

| | **Зәкәт** |
|---|---|
| 1. | Зәкәтнең әһәмияте һәм файдасы |
| 2. | Кемнәр зәкәт түләргә тиеш |
| 3. | Нисаб |
| 4. | Зәкәт кемгә түләнә |

| | |
|---|---|
| 5. | Зәкәт түләнми торган мал |
| 6. | Зәкәт түләнә торган мал. Зәкәтнең күләме |
| 7. | Зәкәт түләмәүнең җәзасы |
| 8. | Сораулар һәм биремнәр |
| | **Хаҗ** |
| 9. | Хаҗның әһәмияте һәм файдасы |
| 10. | Кемнәргә һәм кайчан хаҗ кылу фарыз |
| 11. | Хаҗның төрләре |
| 12. | Ихрам. Тәлбия. Тәваф. Сагй. Вәкфә |
| 13. | Хаҗ ничек кылына |
| 14. | Гомрә |
| 15. | Сораулар һәм биремнәр |
| | **Корбан** |
| 16. | Корбан чалуның әһәмияте |
| 17. | Кемнәргә корбан чалу фарыз |
| 18. | Корбан чалу ничек һәм кайчан башкарыла |
| 19. | Корбан итеп чалынган хайванның ите һәм тиресе белән ни эшләргә |
| 20. | Нәзер корбаны |
| 21. | Корбан итеп чалырга рөхсәт ителгән һәм рөхсәт ителмәгән хайваннар |
| 22. | Хәләл һәм хәрам ит |
| | **Бала туу белән бәйле йолалар** |
| 23. | Азан һәм камәт уку |
| 24. | Тәһник |
| 25. | Башындагы чәчен кыру |

| | |
|---|---|
| 26. | Гакыйкә корбаны |
| 27. | Исем кушу |
| 28. | Баланы сөннәткә утырту |
| 29. | Балага күз тидерү |
| | **Ант итү һәм аны үтәү** |
| | **Изге айлар һәм мөбарәк көннәр белән кичәләр** |
| 30. | Җомга |
| 31. | Рамазан вә Корбан бәйрәмнәре |
| 32. | Мәүлид – Мөхәммәд Пәйгамбәрнең *1* туган көне |
| 33. | Мөхәррам ае |
| 34. | Гашүрә |
| 35. | Раҗәп ае |
| 36. | Рагаиб кичәсе |
| 37. | Исра һәм миграҗ төне |
| 38. | Шәгъбан ае һәм Бәраәт кичәсе |
| 39. | Кадер кичәсе |

**Төп әдәбият:**

1. Ислам дине нигезләре – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2016.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Максуди Ә. Гыйбадәте исламия. — Казан: Идел-Пресс, 2013.

## 4. Гакыйдә (исламда дөньяга караш) буенча тематик план

**I өлеш**

| № | Тема |
|---|---|
| 1. | Гакыйдә фәне турында гомуми мәгълүмат, вәгазь. |
| 2. | Ислам гакыйдәсенең төп принциплары (мөселманның дөньяга карашы асылы). |
| 3. | Гакыйдәнең чыганаклары һәм нигезе. |
| 4. | Ислам гакыйдәсенең әһәмияте. |
| 5. | Гакыйдә фәнендә “иман” мәсьәләсе: ислам, иман, ихсан төшенчәләре. |
| 6. | Ислам дине баганалары – ислам гакыйдәсе аңлатмасында. |
| 7. | «Ләә иләһә илләә Аллаһү» кәлимәсенең тәрҗемәсе һәм мәгънәсе. |
| 8. | «Мүхәммәдүр расүлүллаһ» кәлимәсенең тәрҗемәсе һәм мәгънәсе. |
| 9. | Өстәмә: Мөхәммәд (с.г.в.с.) турында кыскача төп мәгълүмат (тәрҗемәи хәле хронологиясе). |
| 10. | Шәһәдәтне бозучы сәбәпләр. |
| 11. | «Гыйбадәт» төшенчәсе (нәрсә ул гыйбадәт?) Гыйбадәт кабул булыр өчен шартлар. Намаз фазыйләтләре (кыскача яздыру һәм вәгазь). |
| 12. | Кешеләрнең дөньяга карашлары буенча бүленүе (кем ул мөселман, хакыйкый мөэмин-мөселман, кәфер, мөшрик, мәҗүси, фәсикъ монафыйк. Монафыйкларга хас булган сыйфатлар). |
| 13. | Иманның асылы. |
| 14. | Иманны ныгыту ысуллары. |
| 15. | Аллаһка ышану: кем Ул Аллаһ? (“Аллаһ” төшенчәсе буенча кайбер аңлатмалар). |
| 16. | Аллаһка ышанырга этәрә торган төп сәбәпләр. |
| 17. | Аллаһы Тәгаләнең барлыгы турында 3 фикер. |
| 18. | Аллаһы Тәгаләнең берлеге турында |

| | |
|---|---|
| 19. | Аллаһы Тәгаләнең гүзәл исемнәре (гомуми аңлатма). Аллаһ исемнәрен белүнең әһәмияте. |
| 20. | Аллаһның барлыгына дәлилләр (тәфсилләп һәм кыскача нәтиҗәләр рәвешендә). |
| 21. | Аллаһ Раббыбызның кайбер могҗизалы галәмәтләре. |
| 22. | Аллаһы Тәгаләгә ышануның йогынтысы. |
| 23. | Кабатлау. |

**II өлеш**

| | |
|---|---|
| 1. | Өйрәнгәннәрне кабатлау (иман нигезләре), вәгазь. |
| 2. | Фәрештәләргә ышану – иман шартларының берсе (гомуми аңлатма). Фәрештәләр турында төп мәгълүмат. Фәрештәләргә ышануның әһәмияте. |
| 3. | Аллаһы Тәгалә китапларына ышану – иман шартларының берсе (гомуми аңлатма). Изге китапларның иңү сәбәбе. |
| 4. | Безгә мәгълүм булган изге китаплар (Тәүрат, Зәбүр, Инҗил, Коръән һәм сәхифәләр), алар кайсы пәйгамбәрләр аркылы иңдерелгән, иңдерүнең тарихы, максаты (кыскача мәгълүмат). |
| 5. | Барлык изге китапларны берләштерүче хасиятләр. Коръәннең үзенчәлекләре. Коръәнгә хәтле иңдерелгән изге китапларга бүген хас булган үзенчәлекләр. |
| 6. | Коръән турында 3 фикер («Гарәпләр язган»; «Мөхәммәд (с.г.в.с.) язган»; «Аллаһ иңдергән»). Коръәннең илаһи, изге китап икәнлегенә дәлилләр. |
| 7. | Пәйгамбәрләргә ышану – иман шартларының берсе (гомуми аңлатма). Пәйгамбәрләр җибәрелүнең максаты (пәйгамбәрлекнең асылы). Коръәндә искә алына торган пәйгамбәрләр. |
| 8. | Пәйгамбәрләргә хас булган сыйфатлар. Нәби һәм рәсүл төшенчәләре, аермасы. |
| 9. | Мөхәммәд (с.г.в.с.) үзенчәлекләре һәм могҗизалары. |
| 10. | «Фәрештәләргә, изге китапларга һәм пәйгамбәрләргә ышану» темалары буенча нәтиҗә дәресе: семинар яки язма эш (семинар – өйрәнелгән темаларны искә төшереп, бергәләп сөйләшеп алу). |

| | |
|---|---|
| 11. | Кыямәт көненә ышану – иман шартларының берсе: кереш (гомуми мәгълүмат). “Әлбарзах” төшенчәсе. |
| 12. | Үлем һәм кабердәге халәт турында: иманлы һәм имансыз кешенең кабердәге хәле; кабер кысуы; кабердәге сораулар. Кешенең үлемнән соң хәле турындагы кайбер дәлилләр. Кабер газапларының сәбәпләре. Кабер газабыннан котылучылар. |
| 13. | Кыямәт көне исемнәре. |
| 14. | Кыямәт көненең галәмәтләре (гомуми аңлатма). |
| 15. | Инде булган һәм кабатланмаячак галәмәтләр. |
| 16. | Булган һәм кабатланып тора торган галәмәтләр. |
| 17. | Әле булмаган (киләчәктә булырга тиешле) кече галәмәтләр. |
| 18. | Кыямәт көненең зур галәмәтләре (гомуми аңлатма). Беренче галәмәт – Духан; |
| 19. | Икенче галәмәт – Дәҗҗал; |
| 20. | Өченче галәмәт – Гайсә (г.с) нең икенче тапкыр җиргә килүе; |
| 21. | Дүртенче галәмәт – «Йәъҗүҗ-Мәъҗүҗ» кавемнәре; |
| 22. | Бишенче галәмәт – Даббә; Алтынчы галәмәт – Кояшның бату җиреннән чыгуы; Җиденче, сигезенче һәм тугызынчы галәмәтләр – Өч зур афәт; Унынчы галәмәт – Кешеләрне җыячак ут. |
| 23. | «Кыямәт көне» темасы буенча (гомуми аңлатмадан башлап Зур галәмәтләргә кадәр) нәтиҗә ясау дәресе (семинар яки язма эш). |

## III өлеш

| | |
|---|---|
| 1. | «Кыямәт көненә ышану» темасы буенча өйрәнелгәнне кабатлау, сорау-җавап, вәгазь. |
| 2. | Кыямәт көне башлануы: Сүргә өрү (гомуми мәгълүмат). Сүрнең аңлатмасы (нәрсә ул сүр?). Сүргә өреләә торган көн. Ничә мәртәбә өреләә (2 фикер). Беренче сүргә өрелгәннән соң үлмәүче мәхлуклар. |
| 3. | Җирдән кубарылып чыгу һәм мәхшәр мәйданына җыелу; җыелуның күренешләре. Мәхшәр җирен сыйфатлау. |

| | |
|---|---|
| 4. | Үлгәннән соң терелүгә Коръәндәге кайбер дәлилләр. Кешенең бу дөньядагы нинди сыйфатлары ахирәттә үзгәрәчәк. |
| 5. | Кешеләрнең Кыямәт көнендәге хәлләре:<br><br>Гөнаһлы мөселманнарның хәлләре: зәкәт бирмәүчеләр; тәкәбберләр; вәгъдәсендә тормаучылар; җирне рөхсәтсез алучылар; ике йөзлеләр; кеше сүзен астыртын тыңлаучылар; байлыгы була торып кешеләрдән сәдака сорап йөрүчеләр; үз вазыйфаларын тиешенчә башкармаучы хуҗа (хаким). |
| 6. | Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә игътибар бирмичә кемнәр белән бөтенләй сөйләшмәс. |
| 7. | Тәкъва кешеләрнең Кыямәт көнендәге хәлләре (гомуми аңлатма). Аллаһ күләгәсе астында булачак 7 төр төркем. |
| 8. | Мөселман кардәшләренә ярдәм итүчеләр; үз гаиләләрендә һәм кешеләр арасында гадел булучылар; шаһитләр һәм сакчылар; үз ачуларын баса алучылар; Кыямәт көнендә мөәзиннәрнең өстенлеге; тәһарәтнең фазыйләте. |
| 9. | Кыямәт көнендә кәферләрнең хәлләре (гомуми аңлатма). Кәферләр дөньяда кылган яхшы гамәлләрнең югалуы (дәлилләр). |
| 10. | Җәһәннәм әһелләренең бер-берсе белән низаглашулары. |
| 11. | Шәфәгать (гомуми аңлатма). Шәфәгать төрләре. |
| 12. | Сират күпере. |
| 13. | Җәннәт (гомуми аңлатма). Җәннәт нигъмәтләре. |
| 14. | Җәһәннәм (гомуми аңлатма). Җәһәннәм газаплары. |
| 15. | Җәннәт әһелләренең җәһәннәм әһелләре белән сөйләшүләре. |
| 16. | Ахирәткә иман китерүнең файдалары. |
| 17. | Гомум “Кыямәт көне” темасы буенча семинар яки язма эш. |
| 18. | Тәкъдиргә иман китерү – иман шартларының берсе. Када вә кадәр. |
| 19. | Тәкъдир ул – Аллаһы Тәгаләнең бөтен нәрсәне үз эченә ала торган мәңгелек белеме. |
| 20. | Ләүһүл-мәхфүз. |

| | |
|---|---|
| 21. | Аллаһы Тәгалә – ихтыяры һәм кадирлеге бөтен нәрсәгә үтеп керә ала торган Яратучы. |
| 22. | Тәкъдир нигезендә булган нәрсә – Аллаһның бөек сере. |
| 23. | Төрле мәсьәләләрне хәл иткәндә ике юл тәкъдим ителүе һәм сайлау хокукы. |
| 24. | Тәкъдир мәсьәләсендә кеше гамәлләренең бүленүе (мәҗбүрилек – ихтыярлылык). |
| 25. | “Ризк” төшенчәсе. |
| 26. | “Хәрам гамәлләр кылуым – Аллаһның тәкъдире ул” – дип әйтүчеләргә җавап. |
| 27. | Дога кылу хакында. |
| 28. | Тәкъдиргә иман китерүнең файдасы. |
| 29. | Кабатлау, нәтиҗә чыгару. |

**Төп әдәбият:**

1. Ислам дине нигезләре – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2016.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Вәлиуллин К. Ислам гакыйдәсе (Иман нигезләре). Укыту әсбабы. Казан: “Мөхәммәдия” мәдрәсәсе, 2012.

2. Әдһәмов Г. Гакыйдә (Иман нигезләре). Уку әсбабы. Казан: «Хузур» нәшрияты, 2014.

# 5. Ислам тарихы

## 5.1. *Мөхәммәд пәйгамбәрнең (с.г.в.с.) тормыш юлы*

| № | Тема |
|---|---|
| 1. | Мөхәммәднең тууы һәм аның балачагы |
| 2. | Абзыйсы белкасыймән Шәм иленә бару |
| 3. | Мөхәммәднең кайбер сыйфатлары |
| 4. | Хилф Әл-Фудул (Фазыйләтлеләр берлеге) |
| 5. | Кәгъбәне төзү |
| 6. | Хәдичәгә өйләнүе |
| 7. | Вәһи иңә башлавы |
| 8. | Исламга чакыра башлау |
| 9. | Беренче мөселманнар |
| 10. | Мөселманнарны җәзалау |
| 11. | Хәмзә ибн Габдел-Моталлиб Ислам динен ничек кабул иткән |
| 12. | Ничек итеп корәешлеләр Пәйгамбәргә вәкил җибәргәннәр |
| 13. | Эфиопиягә күчеп китү |
| 14. | Гомәр ибн Әл-Хаттаб Ислам динен кабул итә |
| 15. | Һашим ыруында баш күтәрү |
| 16. | Хәсрәт елы |
| 17. | Тайфка бару |
| 18. | Мөхәммәднең Мәккәдән Иерусалимга төнге сәяхәте һәм аның күккә ашуы |
| 19. | Һиҗрәт хакында уйланулар |
| 20. | Мәдинәдә Ислам таралу |
| 21. | Мөхәммәдне үтерергә омтылу |
| 22. | Аллаһ Илчесенең мәчеттәге вәгазе |

| | |
|---|---|
| 23. | Мәдинәдәге мөселманнар тормышыны үзенчәлекле сыйфатлары |
| 24. | Бәдер сугышы |
| 25. | Бәдер әсирләре |
| 26. | Кайнукаг кабиләсен күчерү |
| 27. | Могжиза |
| 28. | Өхед сугышы |
| 29. | Нәдир кабиләсенә каршы сугыш хәрәкәтләре |
| 30. | Чокыр сугышы |
| 31. | Хөдәйбия сугышы |
| 32. | Кем ул Өмме Сәләмә |
| 33. | Хөдәйбия килешүе нәтиҗәләре |
| 34. | Патшаларга һәм дәүләт башлыкларына хатлар |
| 35. | Пәйгамбәрнең Һиракылга хаты |
| 36. | Хайбәргә яу белән бару |
| 37. | Аллаһ бүләк иткән гыйбадәт |
| 38. | Халид ибн әл–Вәлиднең Исламны кабул итүе |
| 39. | Мүтә сугышы |
| 40. | Мәккәне яулап алу алдыннан |
| 41. | Хөнәеннәргә каршы яу |
| 42. | Тайфка яу белән бару |
| 43. | Һәвәзиннәр вәкиллеге |
| 44. | Вәкиллекләр һәм вакыйгалар |
| 45. | Тәбук– соңгы яу урыны |
| 46. | Әбу Бәкернең хажга баруы |
| 47. | Хушлашу таңы |

| | |
|---|---|
| 48. | Үсәмә ибн Зәед гаскәре |
| 49. | Расүлүллаһның авыруы |
| ***5.2. Тугры хәлифәләр тормышы*** | |
| 50. | Тугры хәлифәләр: Әбү Бәкр Әс-Ситдыйк (р.г.). |
| 51. | Тугры хәлифәләр: Гомәр әл-Хаттаб (р.г.). |
| 52. | Тугры хәлифәләр: Госман бине Гаффан (р.г.). |
| 53. | Тугры хәлифәләр: Гали бине Әбү Талиб (р.г.). |
| ***5.3. Татарларда ислам дине тарихы*** | |
| 54. | Ислам диненең Идел буена үтеп керүе һәм таралуы |
| 55. | VIII – XIII гасырларда Урта Иделдә Ислам |
| 56. | Алтын Урда чорында Ислам |
| 57. | Татар ханлыкларында Ислам |
| 58. | Россия империясендә Ислам |
| 59. | СССРда Ислам |
| 60. | Татарстанда Исламның бүгенге хәле |

**Төп әдәбият:**

1. Ислам дине нигезләре – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2016.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Бикбулат С.  Хәзрәти Мөхәммәд. – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2014.
2. Фәхреддин Р. Мөхәммәд. – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2015.

## 6. Әдәп-әхлак (мөселман әдәбе вә әхлагы) буенча тематик план

### I өлеш

| № | Тема |
|---|---|
| 1. | **Нәрсә ул әхлак?** (“Әхлак” төшенчәсе турында гомуми аңлатма). |
| | **Әхлак һәм әхлак вазифаларыбыз** |
| 2. | Алаһы Тәгаләгә һәм пәйгамбәребезгә карата булган вазифаларыбыз. |
| 3. | Үзебезгә карата булган вазифаларыбыз. |
| 4. | Гаиләбезгә карата булган вазифаларыбыз. Ата-ананың балаларына карата булган вазифалары. Балаларның ата-аналарына карата булган вазифалары. |
| 5. | Туганнар һәм кардәшләрнең бер-берләренә карата булган вазифалары. |
| 6. | Ватан вә милләтебезгә карата булган вазифаларыбыз. |
| 7. | Бөтен кешелеккә карата булган вазифаларыбыз. |
| **Җәмгыятьтә әдәплелек кануннары буенча яшәү** | |
| 8. | Ашау һәм эчү әдәпләре. |
| 9. | Сәламләү әдәбе. |
| 10. | Кеше йортына керү кагыйдәләре. |
| 11. | Бер бинада җыелган кешеләрнең үз-үзләрен тоту кагыйдәләре. |
| 12. | Сөйләм әдәбе. |
| 13. | Шаярту әдәбе. |
| 14. | Котлау әдәбе. |
| 15. | Сырхауның (авыруның) хәлен белү әдәбе. |
| 16. | Кайгы уртаклашу әдәбе. |
| 17. | Иснәгәндә һәм төчкергәндә үтәлергә тиешле кагыйдәләр. |
| **Яхшы хәлләр – күркәм холыклар** | |
| 18. | Тугрылык. |

| | |
|---|---|
| 19. | Тырышлык. |
| 20. | Мәрхәмәт вә йомшак күңеллелек. |
| 21. | Ярдәмләшү вә юмартлык. |
| 22. | Әдәп вә хая. |
| 23. | Дуслык вә иптәшлек. |
| 24. | Сабырлык. Сабырлыкның төрләре. |
| 25. | Шөкер итү. |
| 26. | Олыларга хөрмәт, сабыйларга сөю. |
| 27. | Хак. |
| 28. | Адәләт. |
| 29. | Әманәт. |
| 30. | Вәгъдәдә тору. |
| 31. | Тәүбә. |
| **Начар хәлләр – ямьсез холыклар** | |
| 32. | Ялган вә хәйлә. |
| 33. | Гайбәт сөйләү – кеше яманлау. |
| 34. | Урлау. |
| 35. | Кеше үтерү. |
| 36. | Аракы эчү. |
| 37. | Отышлы уеннар уйнау. |
| 38. | Зина кылу. |
| 39. | Ифтира – яла ягу. |
| 40. | Тәкәбберлек. |
| 41. | Исраф. |
| 42. | Хөсет вә көнчелек. |

| | |
|---|---|
| 43. | Гөнаһ. |
| **Дини йолаларыбыз** | |
| 44. | Балага исем кушу. |
| 45. | Ир балаларны сөннәткә утырту. |
| 46. | Сәламләшү. |
| 47. | Бәйрәм вә бәйрәм белән котлау. |
| 48. | Корбан чалу йоласы. |
| 49. | Хаста зиярәте (авыру кешенең хәлен белү). |
| 50. | Кабер зиярәте. |
| 51. | Никах вә өйләнү. |
| **Дини бәйрәмнәр һәм истәлекле көннәр** | |
| 52. | Җомга көн. |
| 53. | Ураза вә Корбан бәйрәмнәре. |
| 54. | Гашура көне. |
| 55. | Изге айлар вә изге кичәләр: Рәҗәп, Шәгбан вә Рамазан айлары. |
| 56. | Рагаиб кичәсе. |
| 57. | Миграҗ кичәсе. |
| 58. | Бәраәт кичәсе. |
| 59. | Кадер кичәсе. |
| 60. | Мәүлид кичәсе. |

**Төп әдәбият:**

1. Ислам дине нигезләре – Казан: «Хузур» нәшрияты, 2016.